• КЫЙССА •
ИБРАҺИМ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ
*5 бит*

• СОРАУ-ҖАВАП •
ИМАН АРТАМЫ?
*7 бит*

• САБЫЙГА •
ДИН – БӘХЕТКӘ ЮЛ
*9 бит*

• ӘДӘБИ СӘХИФӘ •
ӘНИ ДИМИМ...
*14 бит*

*№ 6 (299)* *Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы* *шәүвәл-зөлкагъдә 1441*

*Июнь, 2020*

دين و معيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Ислам динендә ришвәтчелеккә




Ришвәтчелек турында Ислам ни әйтә соң? Коръәни Кәримдә бу гамәл катгый рәвештә тыела. Аллаһы Тәгалә болай ди:

**«Бер-берегезнең малларын (риба, талау кебек һәм, гомумән, Аллаһы кушмаган) нахак (юллар) белән ашамагыз. (Ялгышлыгын һәм гөнаһлылыгын) Үзегез белә торып, кешеләрнең бер өлеш малларын гөнаһ белән ашавыгыз өчен хакимнәргә бирмәгез».**
«Әл-Бәкара / Сыер»,2:188

*Дәвамы 4 нче биттә*

# Игелек сагында

**Нәзарәт Казан приютында көн саен 300 мохтаҗны кайнар ризык белән тәэмин итә**



Татарстан мөфтияте тарафыннан Казан шәһәренең Борһан Шаһиди урамы, 26нчы йорт адресы буенча урнашкан «Мохтаҗларга ярдәм күрсәтү» комплексында көн саен 300 мохтаҗ кешегә кайнар ризык таратыла. Әлеге социаль эшчәнлек Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районы мөхтәсибәте, халык ярдәме һәм иганәчеләр тырышлыгы белән тормышка ашырыла. Һәр көнне бирегә сәгать 10да 150 порция иртәнге аш, сәгать көндезге икедә шулай ук 150 порция төшке аш китерелә. Ул бер тапкыр кулланылышта йөрүче савыт-сабага бүленә һәм караучысыз калган өлкәннәргә, авыр хәлдә калучыларга, инвалидларга, аз керемле, күп балалы гаиләләргә таратыла. Шулай итеп, Нәзарәт башлангычында һәм мөхтәсибәт җитәкчелегендә тормышка ашырылучы әлеге социаль эшчәнлекнең әһәмияте Рамазан аенда, җәмгыятьтән үз-үзеңне читләштерү чорында башланып киткән иде һәм бүген дә дәвам итә.

Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районы имам-мөхтәсибе Йосыф хәзрәт Дәүләтшин «Мохтаҗларга ярдәм күрсәтү» комплексы эшчәнлеген киңәйтү планнары белән уртаклашты. Киләчәктә үзәккә автобус сатып алу һәм шәһәрдә 4-5 урында график буенча мохтаҗларга ризык таратып ашату планлаштырыла.

Кайнар ризык белән тәэмин итүдән тыш, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды приютка мохтаҗларга бушлай тарату өчен кием-салым да китереп тапшыра. Шушы эшкә Казан мәчетләре, шул исәптә Кабан арты мәчете дә кушылды. Йосыф хәзрәт киләчәктә Кабан арты мәчетендә барлык таләпләргә җавап бирерлек итеп азык-төлекне, ярмаларны, яшелчәләрне саклау өчен склад булдыру ниятләре белән уртаклашты.

Мөфтиятнең әлеге комплекс белән эшчәнлеге даими рәвештә алып барыла. Мисал өчен, Рамазан аенда нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды ярдәме белән VIII Республикакүләм ифтар кысаларында әлеге үзәккә көн саен 400гә кадәр ифтар җыелмалары тапшырылды. Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районы мөхтәсибәте аерым үзе өстәп көн саен тагын 400 порция күләмендә кайнар ифтар ризыгы таратуны оештырды. Моннан тыш, узган айда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин тарафыннан йорт-җирсез калган, сукбай кешеләргә юыну мөмкинлеге тудыру өчен өстәмә бер павильон бүләк ителде. Комплексның эшчәнлеге «Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге» Автономияле коммерцияле булмаган оешма белән Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте арасында төзелгән килешү нигезендә алып барыла.

■ **dum.rt**

# Мохтаҗ гаиләләргә ярдәм

**Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды авыру балалары булган мохтаҗ гаиләләргә азык-төлек таратты**



Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды авыру балалары булган мохтаҗ гаиләләргә азык-төлек өләшүне дәвам итә.

Узган атна башында ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды хезмәткәрләре Балтач районына 100 данә һәм фонд карамагында тәрбияләнүче 50 казанлыга азык-төлек җыелмалары тапшырды.

Азык-төлек җыелмасына он, ярмалар, көнбагыш мае, консерва, тәмтомнар, шикәр, макарон һәм чәй кертелде. «Зәкят» хәйрия фонды тәрбиясендә булганнарга җыелмалар бушлай бирелде.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, элеккеге кебек үк, акцияне тормышка ашыруда шулай ук шәхси автомибильләре булган яшь автоволонтерлар да актив катнашты. Эшкә керешер алдыннан ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды хезмәткәрләре һәрвакыттагыча барлык ихтыярчыларны битлекләр, перчаткалар, антисептик белән тәэмин итте һәм азык-төлекне өйләргә өләшеп йөрү буенча инструктаж уздырды.

Акциядә катнашырга теләүчеләр матди ярдәм күрсәтә ала: акчаны Сaклык банкы картасы номеры буенча 4817 7601 6652 0787 (карта хуҗасы – «Зәкят» хәйрия фонды хезмәткәре Борһанова Майя Атамуратовна) җибәрергә мөмкин.

Безнең сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам болай дигән: «Яшермә, юкса Аллаһы Тәгалә сиңа бирергә мөмкин нәрсәләрне синнән яшерер, мөмкинлегеңә карап, Аллаһы юлында сарыф ит».

Аллаһы Тәгалә изге гамәлләрне кабуллардан кылса иде!

■ **dum.rt**

# «Мөхәммәдия» шәкертләре дипломлы булды

**Мөфти «Мөхәммәдия» шәкертләренә дипломнар тапшырды. Барлыгы быел Татарстандагы ислам уку йортларын 700гә якын шәкерт тәмамлый**



18нче июньдә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең көндезге бүлек шәкертләре, чыгарылыш имтиханнарын тапшырып һәм диплом эшләрен уңышлы яклап, югары дини белем алу хакында дипломнар алды. Биш ел дәвамында уку йортында белем алган укучыларга дипломнарны Татарстан мөфтие һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең җитәкчесе Камил хәзрәт Сәмигуллин тапшырды. Барлыгы 8 укучы – дүрт егет һәм дүрт кыз шәригать фәннәрен үзләштереп, мөфти кулыннан таныклыклар алды һәм дини хезмәткә әзер булуларын белдерде. Берләттән мәдрәсә кысаларында 3 ел элек барлыкка килгән тәхфиз (Коръән ятлау) бүлеген тәмамлаган беренче җиде шәкерткә дә шәһадәтнамәләр тапшырылды. Әлеге бүлектә шәкертләр 3 ел дәвамында белем алып, Кәлам Шәрифне тулысынча ятлап, нәзарәт комиссиясенә имтиханнар тапшырып, барысы – дүрт егет һәм өч кыз Коръән-хафиз булдылар. Аларга мөфтият тарихында беренче тапкыр бирелә торган документларны нәзарәтнең Коръән-хафизларны тикшерү комиссиясе рәисе Илнур хәзрәт Хәйруллин тапшырды. Диплом һәм шәһадәтна-мәләрне тапшыру тантанасы коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау өчен Роспотребнадзор тарафыннан тәкъдим ителгән барлык чараларны да истә тотып оештырылды.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин башлангычы белән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә моннан өч ел элек булдырылган Коръәнне ятлау бүлеге үзенең уңай нәтиҗәләрен бирде. Камил хәзрәт, чыгарылыш укучыларын тәбрикләп, үз чыгышында Аллаһының Китабын ятлауга һәм өйрәнүгә зур әһәмият бирергә чакырды:

– Имам Нәвави болай дигән: «Коръән ятламаган кешегә зур галимнәребез фикһ, хәдис кебек шәригать фәннәреннән дәресләр бирмәгән». Иң беренче баскыч – Коръәнне ятлау. Имам Мөхәммәд Шәйбани бервакыт Әбү Хәнифә янына килгәч, Әбү Хәнифә аңа болай дип әйтә: «Хафиз булмасаң, сине кабул итмим». Шуңа күрә имам Мөхәммәд кире кайтып, Коръәнне ятлый, аннары гына Әбү Хәнифә аны шәкертлеккә кабул итә. Бездә йөз еллар элек, инкыйлабка кадәр хафиз булмаган бер галимне дә таба алмассыз. Мәсәлән, Мәрҗани хәзрәтебез, Изге Китапны кабатлау ниятеннән, көн саен өч җөз укый торган булган. Бөтен китаплар һәм барлык фәннәр бер китапны – Коръәнне аңлау өчен укыла. Без ни өчен сарыф фәнен үзләштерәбез? Коръәнне аңлау өчен. Бөтен китапларыбыз – гакыйдә, фикһ һ.б. Коръәнгә кайта. «Мөхәммәдия»дә биш ел укысак та, илле ел укысак та, бары бер Китапны аңлар өчен укыйбыз. Хәзер бер кеше чыгып: «Мин зур галим, ләкин мин Коръәнне белмим», – дисә, аның нигезе юк. Безнең ун кыйраәт буенча да китапларыбыз бар, Аллаһыга шөкер. Халкыбыз арасында ун кыйраәтне белгән хафизлар да булган. Муса Бигиев болай дип әйтә: «Һәрбер мәдрәсәдә һәр шәкерт иң ким дигәндә шатыбия дәрәҗәсендә булса да кыйраәтләрне белергә тиеш». Шатыбия – җиде кыйраәт буенча китап дигән сүз. Димәк, гади генә бер шәкерт җиде кыйраәтне белергә тиеш дигән сүз.


Моннан тыш, үз чыгышы барышында, Камил хәзрәт Сәмигуллин, мәдрәсәдә яңа бүлекләр ачуның матур традициясен дәвам иттереп, киләчәктә ислам сәнгате, каллиграфия буенча белгечләр әзерли торган бүлекләр булдыру өчен дә тәкъдимнәрен җиткерде.

Мөфти чыгышыннан соң тәбрикләү өчен сүз остазларга бирелде, алар имам-хатыйб һәм ислам дине нигезләре мөгаллиме белгечлеген алып чыккан шәкертләргә өммәтебезгә хезмәт кылуда нәсыйхәт сүзләрен җиткерде, киңәшләрен бирде.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсен быел барлыгы 194 шәкерт укып бетерә, шуның 108е – кичке, 71е – читтән торып уку бүлекләрендә белем алучылар. Ә бар Татарстан буенча быел мөселман дини уку йортларын, РИИны да кертеп, җиде йөзгә якын шәкерт гыйлем алып чыга.

■ **dum.rt**

# Татарстанда «Ак кәгазьгә яңа тормыш» акциясе дәвам итә




Җәйнең беренче көнендә Татарстан Диния нәзарәте республикакүләм «Ак кәгазьгә яңа тормыш» макулатура җыю акциясен игълан иткән иде. Акция 2020 елның 1 июленә кадәр дәвам итәчәк. Макулатураны тапшырып алган барлык акча Диния нәзарәтенең «Зәкят» фонды кул астындагы авыр хәлдәге балаларга матди ярдәм булып юлланачак.

Бүгенге көндә Казаннан кала акциягә Татарстанның Әгерҗе, Арча, Чүпрәле, Чистай, Бөгелмә, Кайбыч һәм Әлки районнары кушылды. Алар ярдәме белән 800 кг тирәсе кәгазь җыелды. Шунысы әһәмиятле, бу елны Аллаһы исемнәрен искә алган, Коръән аятьләре һәм хәдисләр кителгән китап һәм кәгазьләр аерым җыела. Акцияне уздыруда мөфтиятнең «Muslimvol» мөселман яшьләре хәрәкәте катнаша, алар аятьләр һәм хәдисләр очраган кәгазьләрне аерып баралар. Алга таба кирәксез китапкәгазьләр махсус кәгазь кабул итә торган оешмаларга тапшырылачак, ә аятьләр һәм хәдисләр очраган кәгазьләр яндырылачак.

Әйтеп узыйк, татарстанлылар гарәпчә һәм иске имля белән язылган борынгы китаплар да китерәләр. Алар өйрәнү өчен белгечләргә тапшырыла.

Макулатураны Габдулла Тукай ур., 89 адресы буенча урнашкан йортка эш көннәрендә 9.00-дан 17.00 сәгатькә кадәр китерергә була. Белешмәләр өчен телефон: +7 (843) 237-86-18; +7(927) 033-31-42.

■ **dum.rt**

# Коръәндә ришвәтчелек турында нәрсә әйтелә?



Ришвәтчелек теге яки бу рәвештә һәр дәүләттә очрый. Рәсәй җәмгыяте өчен дә, кызганычка, бу «чир» билгеле бер күләмдә хас. Ришвәтчелек гадәттә илнең сәяси, иҗтимагый, икътисади проблемаларының нәти-җәсе буларак искә алына. Ә Ислам күзлегеннән караганда, шул ук сәяси, иҗтимагый, икътисади проблемала-рының сәбәпләре әхлаксызлык һәм рухи хәерчелектән килә. Моңа гаҗәпләнәсе юк: кешегә хас булган вәсвәсәгә бирелү, нәфескә иярү турыдан-туры аның намусының һәм вөҗданының дәрәҗәсеннән, күңелендә булган иманыннан тора.

Ришвәтчелек турында Ислам ни әйтә соң? Коръәни Кәримдә бу гамәл катгый рәвештә тыела. Аллаһы Тәгалә болай ди:

**«Бер-берегезнең малларын (риба, талау кебек һәм, гомумән, Аллаһы кушмаган) нахак (юллар) белән ашамагыз. (Ялгышлыгын һәм гөнаһлылыгын) Үзегез белә торып, кешеләрнең бер өлеш малларын гөнаһ белән ашавыгыз өчен хакимнәргә бирмәгез».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:188

Димәк, Аллаһының китабында чит кешенең мал-мөлкәтен хокуксыз үзләштерү харам һәм гөнаһлы санала. Дәүләт хезмәтендә эшләгән затларга ришвәт бирү дә – шул исәптә. Бу аятьтән күргәнебезчә, ришвәтчелек үзе яңа күренеш түгел, ул имансызлыкта, ялгышлык һәм томаналыкта яшәгән әүвәлге дәүләт һәм җәмгыятьләргә хас булган. Аллаһы Тәгалә безгә элекке халыклар арасында таралган ришвәт алу-бирү турында хәбәр итә һәм мөселманнарны охшаш хаталар кылудан кисәтә:

**«(Расүлем!) Алардан күбесенең (ялган кебек зур) гөнаһлар, золымнар һәм (аеруча) харам ашауларда ярышканнарын күрерсең. Һичшиксез, алар кылган нәрсәләр никадәр яман!»**

«Әл-Маидә / Табын», 5:62

Кызганыч ки, мең еллар узса да, бу аять үзенең актуальлеген югалтмый һәм бүгенге заман җәмгыятенең дә әхлак дәрәҗәсен сурәтли. Әмма Ислам тавышы бу кимчелекләрдән сакланырга, алар белән көрәшергә чакырып, югарыдан яңгырый. Динебез иман китерүчеләрне икейөзлелек һәм рибачылык рухи һәлакәткә илтүдән кисәтә:

**«Һичшиксез, Аллаһы индергән (Тәүрат) китабын яшергән һәм аны арзан бәягә алыштырганнар – әнә алар (Тәүратны үзгәртү өчен алган ришвәтләрен ашаганда) карыннарына фәкать ут кына тутыралар. (Ахирәттә дә аларның ризыгы канлы эрен һәм зәкъкум кебек җәһәннәм уты ягулыгы булачак.) Кыямәт көнендә Аллаһы аларга (күңелләренә хуш килә торган бер) сүз әйтмәячәк һәм (гөнаһ керләреннән) аларны пакьләмәячәк. Алар өчен тилмерткеч бер газап (булачак)».**

«Әл-Бәкара / Сыер»,2:174

Аллаһы Тәгалә харам юллар белән җыелган байлыкны Коръәндә бер генә искә алмый, һәм аның өчен кырыс җәза вәгъдә итә. Чөнки кешенең нәфсе, богауда тотмасаң, аны билән ала, тора-бара вөҗдан тавышын ишетмәс итә, үз фикеренең дөреслегенә ныклы рәвештә ышандыра; хәтта төрмә җәзасыннан курку хисен эреткән тынгысыз табыш казанууга этәрә.

### Ахирәт җәзасыннан качып булмый

Кешене җинаять кылудан бу дөньяда котылгысыз җәза алу шарты гына саклап тора, дигән фикер таралган. Әмма соңгы вакытта җәмгыятебезгә рухисызлык ишелде: күңел байлыгын инкяр ителә, атеистик карашлар күтәрелә һәм мал артыннан бертуктаусыз куу максаты алга сөрелә. Боларның барысы да ап-ачык хаклыкны да какшатып, җәмгыятебездә кайвакыт җәзадан читтә калып та була икән бит, дигән нәтиҗәләр чыгарыла башлады! Ә менә Ахирәт җәзасыннан качып булмый, анда һәркем, матди һәм кешеләр арасында булган дәрәҗәсенә карамастан, кылганнарына күрә җавап бирәчәк. Бу турыда Коръәндә болай дип әйтелә:

**«Тыелган булса да, риба алулары һәм (ришвәт кебек гаделсез һәм) ялган (хаксыз юллар) белән кешеләрнең малларын ашаулары сәбәпле (аларны бик күп хәерле нәрсәдән мәхрүм иттек). Араларыннан кяферләргә (Ахирәттә) тилмерткеч бер газап әзерләдек».**

«Ән-Нисә» \ «Хатыннар», 4:161

Бу әхлакый яманлык белән көрәшүдә фәкать репрессив чараларга гына таяну файдасыз икәне көн кебек ачык. Динсезлек карашларын көчләп кертү, атеистик принцип белән яшәешне сөрү кешелекне гадел демократик җәмгыять коруга барыбер этәрмәде, хәтта әхлакый нигезләрне какшатуның, кешенең нәфесен бар нәрсәдән өстен куюның һәм башка ватандашларның хокукларына карата ихтирамны юкка чыгаруның сәбәбе булуга без ачык инандык. Үз тормышыңның гына түгел, башкаларның гомеренә дә хуҗа булу, кешеләрнең язмышларына тәэсир итү, җаның һәм тәнең ни теләсә, шуны кылу... Җәмгыятьнең әхлаксыз һәм динсез булып яшәгән, Аллаһы Тәгаләгә һәм Кыямәт көненә ышанмаган, ахыр чиктә ришвәтчелек һәм җәзасызлык чире белән авырган бәндәләре әнә шушы бозык уңышларга омтыла.

Шул ук вакытта исламның әхлакый һәм кануни тәртипләре бөтен кеше арасында, аның матди хәленә һәм җәмгыятьтәге дәрәҗәсенә карамастан, тигезлек һәм җаваплылык принципларын таләп итә. Кем дә кем хокуксыз эшләрдә гаепләнсә, һәм аның гаебе исбат ителсә, җәзасы котылгысыз һәм газаплы булыр. Рәсүлебез Мөхәммәд галәйһиссәлам нең ришвәтчене ачулы рәвештә искә алган берничә хәдисе бар. Шәригать кануннары буенча ришвәтне бирү дә, алу да гөнаһлы санала. Әхмәд бине Хәнбәл хәдисләре җыентыгынан алынган һәм татар мәгърифәтчесе Ризаэтдин Фәхретдиннең «Җәвәмигуль Кәлим» хезмәтендә китерелгән бер хәдисендә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай ди: «Ришвәт бирүчене һәм алучыны, алар арасында булган арадашчыны да Аллаһы ләгънәт кылды». Расүлебез галәйһиссәлам ришвәтчелекнең дәүләт һәм җәмгыять өчен коточкыч шаукымына: «Ришвәт таралганнар арасында курку чолгап алмаган халык юктыр», – дип игътибар иткән.

### Җәмгыятьне ришвәтчелек чиреннән дәвалап буламы?

Мөселман җитәкчеләре яшәешенә күз салыйк. Гомәр бине Габделгазиз исемле хәлифә (күп галимнәр аны бишенче тугры хәлифә дип саный) алма яраткан. Бер көнне ул мөселман кардәшләре арасында алма ашыйсы килгәнлеген белгерткән. Берничә мизгелдән күршесе аңа бер кәрзин алма җибәргән, әмма хәлифә аны алмаган һәм кире кайтарырга кушкан. Кешеләрнең гаҗәпләнүенә ул: «Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бүләкләр кабул иткән, әмма мин бу бүләкнең ришвәт булуы мөмкин дип курыктым», – дип җавап кайтарган.

Кайсыдыр җирләрнең вәлие Фодаил бине Гыяд: «Әгәр минем Аллаһы кабул итә торган догам булса, мин аны патша өчен кылыр идем, чөнки үзем өчен генә дога кылсам, ул доганың файдасы миңа гына булачак. Солтаныбыз өчен сорасам, һәм ул изгелеккә ирешсә, халык һәм илебез дә изге булыр», – дигән.

Тарих битләрендә гадел һәм киң күңелле булып искә алынган Әнуширван патшасы хакимлеге вакытында аның кулы астында яшәгән бер кеше җир сатып ала. Күпмедер вакыттан соң, бу кеше шул җирдә качырылган хәзинә таба һәм бу хакта ул җирнең элеккеге хуҗасына сөйли. Сатучы аңа: «Сиңа җиремне сатканчы анда бернинди хәзинә тапмаган идем, димәк, алар синеке», – дип җавап биргән. Ләкин яңа хуҗа да: «Чит кешенең байлыгы миңа кирәк түгел, аларны үзеңә ал», – дип, үзенекендә нык торган. Аларның берсе дә үзен табылган хәзинәгә лаек дип тапмаган, шуңа бу бәхәскә гадел чишү табарга дип, алар Әнуширван патшага баралар. Ул бу кешеләрнең гадел булуларына сөенгән һәм, киңәш итеп, балаларын өйләнештерергә һәм хәзинәне яшьләргә бүләк итәргә тәкъдим иткән. Бу тәкъвалык һәм намуслылык мисалы тагы бер кат һәр халыкның нинди җитәкчесе бар, ул шундыйга лаек икәнен исбатлый. Әнуширванның халкы патшаларыннан үрнәк алган һәм гадел дәүләттә гадел яшәгән. Бу дөньяда ришвәт биреп теләгәнебезгә ирешсәк тә, Ахирәттә бәхеттән мәхрүм калуыбыз бар...

**■ Камил хәзрәт Сәмигуллин,**
**Татарстан Республикасы мөфтие**

# Ибраһим галәйһиссәлам кыйссасы

Шәех Сәгъди тапшырган риваятьтә сөйләнгәнчә, Ибраһим галәйһиссәлам кавеме арасында ел да билгеләп үтелә торган бер бәйрәм булган. Аның хөрмәтенә шәһәрдән читтә төрле ярминкәләр һәм күңел ачулар оештырылган. Һәммә халык – ирләр һәм хатыннар, картлар һәм балалар бу тантаналарда яратып катнашкан. Бәйрәм вакытында шәһәр барча адәмнәрдән бушанып, тынып ялгыз кала торган була.

Ибраһим галәйһиссәлам кавеме потларга табынган. Бәйрәмгә китәр алдыннан да бу кешеләр иң беренче чиратта үзләре ясаган потлар янына килеп, ризык калдырганнар. Кайтышлый янә сыннарга сәҗдә кылып, шул ризыкларны үзләре үк ашап та бетергәннәр. Янәсе, шулай итсәләр, аларга бәрәкәт һәм байлык насыйп ителәчәк.

Шушы томана халыкның башлыгы булып Нәмруд торган. Ул Җир барлыкка килгәннән бирле хакимлек иткән дүрт бөек хөкемдарның берсе була. Белгәнебезчә, алар арасыннан Сөләйман галәйһиссәлам һәм Зөлкарнәйн галәйһиссәлам – иманлы, Нәбүкаднәззәр (Бәхтуннәср) һәм Нәмруд имансыз хакимнәр була. Шулай итеп, Ибраһим галәйһиссәламнең дошманы булган Нәмрудның никадәр зур көчкә ия булуын күз алдына китерүе кыен түгел.

Ибраһим галәйһиссәлам үзе исә бәйрәм йөрешләрендә катнашырга теләми. Бәйрәмнән калу өчен, аның халыкны куркытып болай дип кычкыруы хакында әйтелә:

**«Ул йолдызларга караш ташлады да «Һичшиксез, мин (аңладым, сезнең бәйрәм көнегездә) авырыймын», – диде».**

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:88-89

Моны ничек аңларга? Ибраһим галәйһиссәлам чорында кешелекне еш кына йогышлы авырулар баскан. Йогудан куркып, кешеләр чирле кавемдәшләреннән читләшә торган була. Шуңа Ибраһим галәйһиссәламнең сүзләрен ишетү белән халык аның янынннан төрле якка качып китә. Әмма иң актык рәтләрдә барган карт-корылар бу сүзне ишетми кала, һәм алар якынаю белән Ибраһим галәйһиссәлам тагын сүз ката:

**«Ул: «Сез һәм аталарыгыз ап-ачык бер адашу эчендә булдыгыз», – диде».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:54

Ни өчен Ибраһим галәйһиссәлам аларның аталарын искә ала соң? Чөнки кяферләр потларга табынуны болай дип аклаганнар:

**«Алар: «Без аталарыбызны боларга табынган кемсәләр хәлендә таптык (һәм аларга иярдек)!» – диделәр».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:53

Ибраһим галәйһиссәлам карендәшләренә, ата-бабалар шулай табынганга күрә генә сыннар илаһ була алмый, дип аңлата. Ул аларны аңга килергә чакыра: «Аталарыбыз шушы юлны сайлаган дип, ялгышлыкта яшәргә мөмкинме?» – дип әйтә. Ул, үз кардәшләрен хаталанып яшәүдән, томаналыктан коткару өчен, тырышкан.

Кавемдәшләре исә аның бу сүзләренә ачулана – моңарчы бер генә кеше дә ата-бабаларга каршы сүз әйтергә кыймаган иде. Моңа җавап итеп, Ибраһим галәйһиссәлам тәүге тапкыр үз дине турында ачык итеп игълан итә:

**«Ул әйтте: «Юк! (Мин сезнең белән уен уйнамыйм). Сезнең Раббыгыз – күкләрнең һәм җирнең Раббысы, Ул аларны юктан бар итте. Мин исә моңа (дәлил күрсәтә алырлык дәрәҗәдә) шаһитлык итүчеләрдәнмен».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:56

Ибраһим галәйһиссәлам бу сүзләрне йөрәгендәге көчле ышану һәм ихлас иман белән әйтә. Ул кешеләргә: «Аллаһы чиксез куәт һәм кодрәткә ия һәм яратырга сәләтле. Берни дә барлыкка китерә алмаган зат илаһ була аламыни? Сез ничек итеп потларыгызны Раббыга тиң күрә аласыз?» – дип мөрәҗәгать итә.

Аять Ибраһим галәйһиссәламнең шәһадәсе белән тәмамлана. Билгеле, ул җир һәм күкнең яратылганын да күрмәгән, үзенең дә барлыкка килүенә шаһит булмаган. Әмма аның өчен Җиһанда ком бөртегенә кадәр һәрнәрсә Аллаһы Тәгалә тарафыннан барлыкка китерелгәне көн кебек ачык иде. Боларны сукыр гына күрми. Шуннан Ибраһим галәйһиссәлам кавемдәшләре артыннан болай дип әйтеп кала:

**«Аллаһы белән ант итәмен, сезнең (табынуыгызны туктатып, ул һәйкәлләргә) артыгыз белән борылып (бәйрәмгезгә) китүегездән соң, мин, һичшиксез, ул потларыгызга (бер) тозак корачакмын».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:57

Ләкин арттан килүче картлар, балалар һәм гарипләр бу сүзләрне колакларына да элми. Ибраһим галәйһиссәлам тып-тын, бер җан иясе калмаган шәһәргә кайта. Кулына балта алып, ул сыннар янына китә. Мәҗүси кардәшләре гыйбадәт кылган урында 72 пот торган. Алар алтын, көмеш, агач һәм таштан ясалган була. Уртада – иң зур һәм зиннәтле ташлар белән бизәлгән сын, аның янында кечерәкләре урнаштырылган. Һәрберсе янында кешеләр калдырып киткән ризык. Ибраһим галәйһиссәлам болай дип әйтә:

**«Ул илаһлары янына яшеренеп керде һәм әйтте: «(Алдыгыздагы ашамлыкларны) Ашамыйсызмы? Ни булды сезгә? Сез сөйләшмисезме?»**

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:91-92

**«(Кавеме потлар янынннан китеп баргач) Ул (кулына балта алып, сыннар янына килде дә) аларның иң зурысыннан башкаларын ватып чәлпәрәмә китерде (һәм соңыннан балтаны иң зурысының муенына элеп куйды), бәлки, алар аңа мөрәҗәгать итәрләр (дә ул, аларны зур потка сылтап, җиңеп чыгар)».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:58

Бәйрәмнән кайткан халык хәрабәләрне күреп ала:

**«Алар (бәйрәмнәреннән кайтып, потларын мондый хәлдә күргәч): «Кем безнең илаһларыбызга моны эшләгән булса, ул – залимнәрдән», – диделәр».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:59

Дөреслектә, бу кешеләр үз-үзләрен дә яклый алмаган һәм җимереккә әйләнгән буш сыннарга табынган. Әмма алар шуның кадәр караңгы наданлыкка батканнар, хәтта аек акылларын җуеп, сабак алырдай зиһеннәрен дә югалтканнар. Шушы наданлык баткагыннан чыга алмыйча, бу адәмнәр гаеплене эзләү һәм аннан үч алу турында уйлана башлый.

**«Алар: «Без Ибраһим исемле егетнең аларны һәрвакыт (яманлап) телгә алганын ишеткән идек. (Бәлки, бу эшне ул эшләгәндер)», – диделәр».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:60

Ибраһим хакында Нәмрудка хәбәр итәләр. Хәзер инде аны бөтен халык алдында үлем җәзасы көтә.

**«Алар (Ибраһимны (галәйһиссәлам) үзләре алдына чыгарып): «И Ибраһим! Безнең илаһларыбызга моны син эшләдеңме?» – диделәр».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:62

Ибраһим галәйһиссәлам көлемсерәп җавап кайтара:

**«Ул әйтте: «Юк (мин эшләмәдем)! Моны менә бу иң зурлары эшләгәндер, сорагыз үзләреннән. Әгәр алар сөйләшә торган булсалар (сезгә сөйләсеннәр)».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:63

Уйланучы кешеләр бу сүзләрдән хикмәт табарга тиеш иде, чөнки потларның берсе дә сөйләү түгел, селкенә һәм бер-берсенә кул күтәрә алмаулары да һәркемгә аңлашыла. Ибраһим галәйһиссәлам кавемдәшләренә: «Сез ни өчен үз өсләреннән тузанны да сөртә алмаган бу потларга табынасыз?» – дип мөрәҗәгать итә. Кешеләрне бу фикер бер мәлгә аптырата һәм уйландыра, ләкин алар күнегелгән тормыш тәртибен үзгәртергә әзер булмый. Сабырлыгы һәм күркәм холкы белән мәгълүм булган Ибраһим галәйһиссәлам ярсый:

**«(Ибраһим (галәйһиссәлам) Әйтте: «Сез, Аллаһыны калдырып, сезгә бернинди файда да, зарар да китерә алмаган нәрсәләргә табынасызмы әллә? Сезгә дә, Аллаһыны калдырып табынган нәрсәләрегезгә дә тьфу! Һаман да аңламыйсызмыни?»**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:66-67

Күрәсез, Ибраһим галәйһиссәлам көнчыгыштан алып көнбатышка кадәр бөтен җир белән идарә иткән хакимгә һәм аның халкына фидакарьләрчә каршы чыга. Бу вакытта аның таянырдай һәм Нәмруд шикелле кабахәт дошманнан яклардай бер генә иптәше дә, фикердәше дә булмый. Бердәнбер Яклаучысы һәм Ярдәмчесе – Аллаһы Тәгалә. Раббыбызга, Аның кодрәтенә һәм рәхмәтенә чиксез ышану, ныклы иман Ибраһим галәйһиссәламнең тугры юлдашлары була.

*Дәвамы киләсе санда*



■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы мөфтие**

# Хәләллек ризыкка гына кагылмый

Галәмнәрне юктан бар итеп, аларны Үзенең хикмәте белән тәрбияләп торучы Аллаһы Тәгаләгә дан-мактауларыбыз, хак расүлебез Мөхәммәд галәйһиссәламгә күңел төрләребездән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Бер хәдистә Пәйгамбәребез сәлләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кешенең карынына харам керсә, 40 көн буе кылган догасы, укылган намазы кабул булмас», – дип әйткән.

Хәләл – ул рөхсәт ителгән, яраклы дигән сүз. Элек хәләл дигән сүзне ит белән генә бәйләп карыйлар иде. Хәзер исә аның мәгънәсе шактый киңәйде. Рәсәйдә бүген 20 миллионнан артык мөселман яши. Исламча яшәү рәвеше өчен тиешле шартлар кирәк. Хәләл – ул ризык кына түгел, ә эш (кәсеп), хезмәт хакы, сәламәтлек саклау (медицина ярдәме күрсәтү оешмалары), мәгариф, мөселман балалар бакчалары, сәяхәт итү, мөселманнар өчен бассейннар, матурлык салоннары, чәчтарашханәләр, кунакханәләр, косметика һәм киемсалым (мода) да. Соңгы вакытта исә «хәләл тормыш рәвеше» дигән гыйбарә дә барлыкка килде.

Коръәндә Аллаһы Раббыбыз болай дип әйтә:

**«(Чалмыйча җаны чыккан) Үләксә, (хайванны чалган чакта агып чыккан) кан, дуңгыз ите, Аллаһыдан башкасы өчен (яисә, җаны чыкканчы өлгереп, Ислам кушканча) чалынганнардан тыш, буылган (һәм үлгән), (таш, агач кебек әйберләр белән) кыйналган (һәм үлгән), (биектән яки кое кебек бер җиргә) егылып төшкән (һәм үлгән), (башка бер хайван тарафыннан) сөзелгән (һәм үлгән), ерткыч хайван ашап, (җаны чыкканчы өлгереп) чалынганнан тыш, (табынычла торган) тораташлар (һәм потлар өчен корбан китерелә торган урыннарда) бугазланганнар һәм фал уклары белән багучылык итүегез сезгә харам кылынды. Бу – (харамнардан файдалануыгыз) бер гөнаһкярлык.**

«Мәидә / Аш табыны», 5:3

Шулай итеп, мөселманнарга – үләксә, кан, дуңгыз ите, Аллаһы исеме белән суелмаган мал-туар, буып яки башка хайван тарафыннан үтерелгән хайван, югары электр көчәнеше, каты сугу яки биектән егылып төшү сәбәпле үлгән хайван, ерткыч хайваннар һәм ерткыч кошлар ите харам.

Харам дип бары тик ярамаган ит ризыклары гына түгел, ә гомумән алганда, кеше организмына зыян сала торган барлык төр ризыкларны да атарга кирәк, чөнки хәзерге заман галимнәре дуңгыз итенең һәм мөселманча чалынмаган итләрнең составында зыянлы матдәләр барлыгын фәнни яктан да ачыкладылар. Шуңа күрә хәләл дигәч тә, без кеше сәламәтлегенә зыян салмый торган барлык төр ризыкларны да күз алдында тотарга тиеш.

Бер гыйлем иясе: «Без нәрсә ашыйбыз, шуны тәшкил итәбез», – дип әйткән. Харам ризык ашап, без үзебезнең саулыкка гына түгел, балаларыбыз сәламәтлегенә дә зыян салабыз, ягъни нәселебез тамырына үзебез үк балта белән чабабыз.

Харам ризык иман дигән үсентенең тамырын кисә. Тамыры зәгыйфь үсемлек үсә алмаган кебек, әгәр балабызга харам ризыклар ашатып үстерсәк, аның да иманы зәгыйфь кала. Харам кергән карын авыру була, йөкле чакта харам ашаган ананың баласына начар тәэсир күчә. Шуның өчен дә гаилә коргач, ир кешенең иң беренче бурычы – гаиләсен хәләл ризык белән тәэмин итү. Хәләл ризык ашау – Аллаһы кушканны үтәү, ягъни гыйбадәткә тиң гамәл. Коръәндә болай дип әйтелгән:

**«Дәхи кешегә һич нәрсә юктыр, мәгәр үзе кәсеп иткән нәрсәсе генәдер».**

«Нәҗем / Йолдыз», 53:39

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бер хәдисендә: «Иң яхшы кәсеп – хәләл сәүдә яки үз кулың белән эшләп тапкан мал», – дип әйткән. Мөселман булырак, акча эшләүнең хәләл ысулларын куллану һәм харамнан тыелу бик мөһим. Хәзерге дөньяда кешеләргә үзләрен харамнан саклап калу бик авыр, әмма бу мөмкин хәл. Яраткан пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам һәм аның сәхабәләре әлеге мәсьәләдә безнең өчен яхшы үрнәк булып тора. Аллаһының Илчесе болай дип әйткән: «Әгәр кеше хәләл ысул белән табыш ала икән, бу хәйрия һәм шәфкатьлелек гамәле буларак саналачак».

Үзенең гаиләсен тәэмин итүче һәркем рөхсәт ителгән чаралар гына эзләргә тиеш, чөнки нәкъ менә шул чаралар, ягъни ризыкның хәләл яки харам булуы безнең гыйбадәтебезгә һәм Аллаһы юлындагы тырышлыгыбызга тәэсир ясый. Рөхсәт ителмәгән кәсепләргә риба, ришвәт, урлау, ятимнәр малын үзләштерү, сату-алуда гаделсезлек, килешүләрне (вәгъдәләрне) үтәмәү, мөселман кардәшләренә ярдәм итүдә акча эшләү, (чөнки мөселманнар бер-берләренә Аллаһы ризалыгы өчен ярдәмләшеп яшәргә тиешләр), сыра, исерткеч эчемлекләр, тәмәке сатыла торган кибетләр, бозыклыклар тарала торган оешмалар ачу өчен биналарын арендага бирү һ.б. керә.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**«Аллаһы риба белән кергән малны һәлак итә, ә садакасы бирелгән малны арттыра. Рибаны хәләл диюче кәферне Аллаһы сөйми»,**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:276

Гөнаһлы эшләрдә арадашчы һәм катнашучы булган кешеләр, киләчәк Хисап (Кыямәт) көнендә моның өчен җавап бирергә туры киләчәклеге турында онытмасалар иде.

Хәләллек мәсьәләсе турында сөйләшкәндә тыйб (медицина) өлкәсен карап үтик. Тыюлы матдәләр (продуктлар) белән дәваланырга яки үз эчендә тыелган матдәләр булган дару чараларын кулланырга мөмкинме? Әлеге сорауга җавапны без Изге Коръәндә таба алабыз:

**«И, мөэминнәр! Исертә торган эчемлекләр һәммәсе дә, отыш уеннары һәртөрлесе дә, сыннарга гыйбадәт итү – Аллаһыдан башка мәхлүкъларга табыну эшләре, шулай ук ырымлау – багучылык эшләре харам, шәйтан эшләреннән булган пычрак эшләр, һәлак булудан котылу өчен, бу нәҗес эшләрдән ерак булыгыз! Саклансагыз, шаять котылырсыз – өстенлек табарсыз».**

«Мәидә / Аш табыны», 5:90

Бер хәдистә болай диелә: «Аллаһы Илчесе агуны һәм хәләл булмаган даруларны харам кылды».

Бервакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Барысы да Аллаһыдан булганына шик юк. Ул авырулар (чирләр) һәм аларга шифа итеп һәрберсеннән дару иңдерде. Шуңа күрә, Аллаһы коллары, дәваланыгыз, тик дәвалануда тыелган әйберләрне кулланмагыз».

Хәнәфи мәзһәбендә танылган «Әл-Һидәя» китабында түбәндәге юллар язылган: «Исерткеч эчемлекләрне һәм башка тыелган әйберләрне куллануддан баш тарту зарур, чөнки харам булган нәрсәләрне дәвалануда да куллану рөхсәт ителми. Тик бу аның дәвалау үзлекләре турында билгеле булмаса гына. Әгәр аның дәвалау үзлегенә ия булуы билгеле һәм шул ук вакытта башка рөхсәт ителгән чаралар юк икән, ул, дәвалау максатларында файдалану өчен, рөхсәт ителгән булып санала».

Кеше косметик продукцияне тире, тешләре, чәче һәм бөтен организмы сәламәтлеген һәм тән пакьлеген саклау өчен, шулай ук тышкы кыяфәтне үзгәртү өчен куллана. Моңа көнкүреш кирәк-яраклары (шампунь, гельләр, кремнар, лосьоннар, теш пасталары һ.б.) һәм шулай ук бизәнү өчен кулланыла торган башка чаралар да керә.

Косметик продукция төп чималдан һәм төрле кушылмалардан (буягычлар, ароматизаторлар, куерткычлар һ.б.) җитештерелә.

«Хәләл» стандарты буенча косметик продукциянең составы һәм сыйфаты, шулай ук аны җитештерүнең барлык ысуллары диндә рөхсәт ителгәнчә булырга тиеш.

Чисталык һәм гигиена – Ислам диненең иң мөһим шартларының берсе. Шуңа күрә косметик продукция җитештерүдә иң мөһиме – кеше сәламәтлегенә өчен куркыныч янамау һәм җитештерүнең һәр этабында продукциянең гигиена нормаларына туры килүе.

Мөселманнарга бишектән ләхеткә кадәр хәләл тормыш мөмкинлекләрен тәэмин итү – мәгарифне үстерү һәм дини гыйлем алуда ярдәм күрсәтү өчен, беренче чиратта, эшне хәләл шартлары булган балалар бакчалары, мәктәпләр төзүдән башларга кирәк. Сабыйларга хәләл бакчалар бар инде, әлхәмдүлилләһ, хәзер хәләл мәктәпләр төзү өлкәсендә эшлисе бар. Дәүләт катнашыннан башка әлеге процесс, әлбәттә, мөмкин түгел.

Хәләл юл белән сәяхәт кылу һәм хәләл булган шифаханәләр калганнардан нәрсәләре белән аерылып тора соң? Әлбәттә шартлары, дарулары, ашамлыклары хәләл булуы һ.б. белән.

Кием-салымның да хәләл булуы шарт. Ни өчен дигәндә ул киемнең хәләл акчага сатып алынуы, гаурәтләрне каплавы, хәләл чималдан ясалуы (дуңгыз, яисә башка тыелган хайван тиресеннән булмавы), тыелган сурәтләр ясалган булмавы бик мөһим.

Бер хәдистә болай дип тапшырыла: «Сәгъд бине Әби Ваккас радыяллаһу ганһе берзаман Пәйгамбәребезгә: «Йә Аллаһының Расүле! Үтенәм, Аллаһыдан минем барча догаларымны кабул итүен сорасаңчы», – дип мөрәҗәгать итә. Җавап итеп Расүлебез болай дип әйтә: «Догаларыгыз, мөрәҗәгатегез Аллаһыга ирешсен дисәгез, хәләл ризык белән тукланыгыз! Күпчелек харам ризык ашый, харам кием кия. Һәм шуннан соң кулларын күтәреп дога кыла. Андый догалар ничек кабул булсыннар, ди?»

Тагын бер хәдистә: «Әгәр ун дирһәмлек киемнең бер генә дирһәме булса да гаделсез (харам) рәвештә табылган булса, шул киемне киеп укылган намаз кабул түгел», – дип әйтелә.

Коръәндә ачык әйтелгән: «Аллаһы сезгә Үзенең тыйганнары турында төшендерде бит». Галәмне юктан бар иткән Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәү, беренче чиратта, җәмгыятьне савыктыру юлында үтәлергә тиеш. Аллаһы Тәгалә зарар китерә торган нәрсәләрне тыйган (бу турыда безне Бар кылучыдан да яхшырак белүче юк). Коръәни Кәримдә яки Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең сөннәтендә җавап таба алмаслык сораулар юк, шуңа күрә без Аллаһы күрсәткән дөрес юлдан тайпылмыйча «хәләл»не таба алабыз.

**■ Татарстан Республикасы Диния нәзарәтенең «Хәләл» комитеты**

# Рәт арасы ерак дип җәмәгать намазын калдыру



**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Илдәге соңгы вакыйгаларга бәйле рәвештә мәчетләрдә җәмәгать намазларында 1,5 метр ара калдырып уку тәртипкә керде. Кайбер мөселманнар, бу күренешне яңалык дип кабул итеп, намазга йөрми башладылар. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм намаз вакытында арада буш урын калдырмаска кушкан бит. Нәрсә дип җавап бирергә икән аларга?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Чыннан да, намаз укучылар арасында буш урын калдырмыйча, рәтләрне тигезләп басу – көчле сөннәт, ягъни сөннәт мөәккәдә хөкемендә. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Намаз җиткәч, рәтләрегезне тигезләгез, [бер-берегезнең] җилкәләрегезгә ныклы терәлегез. Чынлыкта, рәтләрне тигезләү – намазның камиллеге», – дип әйткән (Имам Мәлик «Мөвәттә»).

Әмма инфекция таралу куркынычы булган чорда бу сөннәттән читләшеп тору тиешле, чөнки шәригатьтә «файда алуга караганда зыянны юк итү хәерлерәк» кагыйдәсе бар.

Намаз вакытында имамга мәчетнең кайсы урыныннан да иярү ярый. Моңа бәйле фикерләрне имам Әс-Сәрахси «Әл-Мәбсут» (2/117) хезмәтендә китерә:

«Мәчет гомуми бер мәйданны тәшкил итә, шунлыктан [михраб янында торган] имамга мәчетнең икенче бер башында торып иярү дә ярый».

Өстәвенә, мәчеттәге имамга урамда, мәчет янәшәсендә басып иярү дә намазны бозмый, бу очракта бары иярүче кеше имамның нинди хәрәкәтләр ясавын белергә тиеш (мәсәлән, тавыш арттыру җайланмалары аша). «Әл-Бәха әр-раик» (1/385) хезмәте авторы Ибне Нөҗәйм болай дип яза: «Әл-Муҗтәбә» китабында болай диелгән: Мәчет ишегалды мәчет статусында һәм анда, рәтләр тоташмаган булса да, имамга ияреп намаз укырга ярый. Әмма [җәмәгать намазы] мәчеттән тыш урында, башка ишегалдында укыла икән, рәтләрне тигезләгән очракта гына имамга ияреexcept рергә ярый». Ягъни мәчеттә яисә мәчет янында булып, иярүче белән имам арасында ара күп булуга карамастан, намаз уку дөрес була. Ә мәчеттән читтә, ягъни җәмәгатьтән читтә булып, имамга ияреп намаз уку ярамый.

Намазга йөрмәүче танышларыгызга да шундый киңәш бирү хәерле булыр: җәмәгать белән намаз уку вәҗибкә якын сөннәт мөәккәдә хөкемендә, ә алар рәтләр арасы белән бәйле сөннәтне калдыруны сәбәп итеп, сөннәтнең мөһим өлешен, ягъни җәмәгать намазын, калдыралар. Рәтләрдә ара калдырмау җәмәгать намазыннан әһәмиятлерәкмени аларга?

Ә Аллаһы – яхшырак Белүче!

# Иман артамы?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Кайберәүләр иман арта яисә кими, диләр. Бу сорауга ачыклык кертегез әле.**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Әһле Сөннәт вәкилләре өчен иман – Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аллаһы Тәгаләдән ирештергәннәренә калеб белән ышану дигән сүз. Кайбер сөнни галимнәр калеб белән ышануга тел белән тасдыйк итүне дә өстиләр. Мондый иман (көферлекнең капма-каршысы) артмый да, кимеми дә.

Имам Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи үзенең «Васыя» китабында болай дип әйткән:

«Иман артмый да, кимеми дә, чөнки иманның кимүен бары көферлекнең артуы, ә иманның артуын бары көферлекнең кимүе итеп кенә күзаллап булыр иде. Ә кем бер үк вакытта көфер дә, иманлы да була ала?»

Ә Исламга тугрылык, Аллаһының кушканнарын үтәүдә тырышлык мәгънәсендәге иман ныгырга һәм көчсезләнергә мөмкин.

Имам Мөхәммәд Заһид Әл-Кәүсари рахимәһуллаһи Әбү Хәнифәнең «Әл-фикһ әл-әбсат» хезмәтенә искәрмәдә болай дип язган: «Иман – ныклы ышану булганлыктан һәм бу ышануда көферлекнең булуы мөмкин булмаганлыктан, барлык мөселманнар да иманда бертигез. Аларның бер-берсеннән өстенлеге бары иманның камиллеген билгеләүче гамәлләрендә. Ә гамәлләрне иманның бер баганасы дип санаучылар хариҗиләр һәм могътәзилиләр карашларыннан уза алмый».

Коръәндә иманның артуы яисә кимүе турында бәян иткән түбәндәге аятьтә исә Аллаһыдан курку һәм ышанулары арту дип аңларга кирәк.

**«Ул – [ия булган] иманнары белән иманнарын арттырсыннар өчен, иман китерүчеләрнең күңелләренә тынычлык [рәхмәт, Аллаһыга һәм Аның расүленә хөрмәт, Исламның хөкемнәренә авышу һәм тартылу] иңдергән Зат. Күкләрнең һәм җирнең гаскәрләре – Аллаһыныкы гына. Аллаһы – [һәрнәрсәне] Белүче, хикмәт Иясе».**

«Фәтех / Җиңү», 48:4

Иманның артуы яисә кимүе мәсьәләсендә аерма бары сүздәге аермага кайтып кала. Хәнәфиләр кебек иман артмый да, кимеми дә дип санаучылар иманның нигезен, ягъни кешене мөселман итә торган барлык сыйфатларга, гамәлләргә ышануны күздә тота. Ә иман арта яисә кими дип санаучылар иманның изге гамәлләрне, шәһадәт кәлимәсен эченә алган камиллеген күздә тота. «Зиначы, иманлы була торып, зина кылмый» (Имам Бохари, 2475; Имам Мөслим, 57) хәдисендә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең зиначының иманлы булуын инкяр итә.

Иманның артуы турында сөйләгән башка аять һәм хәдисләрнең аңлатмасы түбәндәгечә – аларда иң элек Исламга тулысынча ышанып, соңыннан Исламның башка нигезләмәләрен өйрәнеп, аларга аерым-аерым иман китерүчеләр турында сүз бара. Шулай итеп, аларның иманының нигезе, асылы үзгәрешсез калып, иманга кагылышлы детальләр (иманның чагылышлары) гына арта.

Имам Әт-Тәфтазани рахимәһуллаһи «Шәрх әл-гакаид» хезмәтендә болай дип язган: «Иманның артуы турында бәян итә торган аятьләрне Әбү Хәнифә кебек аңлатырга кирәк. Аларның асылы шунда: иман бары ышанырга тиешле күренешләр артканда гына арткан, һәм бу Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм заманында гына шулай булган. Әмма бу бәхәсле мәсьәлә: кешенең яңа бурычлары Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм чоры булмаган заманда да булырга мөмкин».

Үзенең Аллаһы каршындагы яңа бурычларын белә барган саен, кешенең бу бурычларга ышануы арта бара. Бу хәл сәхабәләр чорында шәригать иңә килгән чорда булган, сәхабәләр үзләре ышанырга тиешле яңадан-яңа хөкемнәрне акрынлап белә барганнар. Бу хәл безнең көннәрдә дә булырга мөмкин. Мәсәлән, кеше Ислам динен кабул итә, аны өйрәнә һәм яңа сөнни нигезләмәләргә ышана башлый. Аның иманы гакыйдә буенча алган белемнәре арткан саен арта бара.

Нәтиҗә ясап, түбәндәгеләргә тукталыйк.

1. Көферлеккә капма-каршы мәгънәдә иманның нигезе артмый да, кимеми дә. Бу нисбәттән барлык мөселманнар да бертигез.

2. Исламга тугрылык, Аллаһының кушканнарын үтәүдә тырышлык мәгънәсендәге иман ныгырга һәм көчсезләнергә мөмкин. Моңа нисбәтле рәвештә бөтен мөселманнар да бертигез түгел:

**«И, кешеләр! Һичшиксез, Без сезне [Адәм исемле] бер ирдән һәм [Хәвва исемле] бер хатыннан яраттык. [Һәммәгезнең дә ата-анасы бер булганга күрә, нәсел-чыгыш белән мактануның ни мәгънәсе бар?] Без сезне [бер-берегезгә уйламый-нитми теләсә ни сөйләр өчен түгел] танышуыгыз өчен кавемнәр һәм кабиләләр иттек. Аллаһы хозурында иң кадерлегез – [иң асыл нәселдән булганнарыгыз түгел, Аллаһы Тәгаләнең харамнарыннан сакланган] бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз. Һичшиксез, Аллаһы – [һәрнәрсәне] Белүче, [һәрнәрсәдән] Хәбәрдар».**

«Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:13

3. Иман артуын кеше ышанырга тиешле яңа нигезләмәләр турындагы гыйлем арту белән дә аңлатырга мөмкин. Бу беренче мөселманнарга да, соңгы мөселманнарга да кагыла.

Ә Аллаһы – яхшырак Белүче!

**Булат Мөбәраков,**
**Шәригать бүлегенең җитәкчесе**

# Нәзарәттә Коръән-хафизларга Шәһадәтнамә тапшыру комиссиясе эшли башлады



Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин хәер-фатыйхасы һәм тәкъдиме белән, Диния Нәзарәтендә Коръән-хафизларга шәһадәтнамәләр тапшыру комиссиясе эшли башлады. Әлеге комиссияне булдыруның төп максаты – республикадагы Коръән-хафизларның санын белү, аларның әзерлек һәм белем дәрәҗәләрен тикшерү, хафизлыкка ирешүләрен документ белән раслау. Шулай итеп, нәзарәт комиссиясе елына ким дигәндә бер тапкыр җыелып, Коръәнне тулысынча ятлаучылардан имтиханнар кабул итәчәк. Шунысы әһәмиятле, шәһәдәтнамәне Коръән-Кәримне үзлегеннән ятлаучыларның да имтихан тапшырып алырга мөмкинлеге бар. Комиссия каршында хатасыз, бернинди кимчелекләрсез, барлык кагыйдәләр буенча Коръәнне яттан теләсә кайсы урыннан укып күрсәтеп, имтиханны уңышлы тапшыручылар Коръәнне ятлау турында нәзарәт шәһадәтнамәсенә лаек була. Комиссия каршында ир-атлар һәм хатын-кызлар имтихан тота ала. Имтихан комиссиясе составында – Коръән-хафизлардан торган нәзарәтнең шәригать мәсьәләләре бүлеге хезмәткәрләре, дини уку йортларында хезмәт куючы остазлар. Комиссиянең рәисе – ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең шәригать мәсьәләләре буенча бүлекнең баш белгече Илнур хәзрәт Хәйруллин. Шәһадәтнамәләр тапшыру барышында нәзарәттә Коръән-хафизлар буенча мәгълүмат базасы булдырылачак, ә бу исә, үз чиратында, Рамазан айларында тәравих намазларын алып бару өчен үзебезнең төбәк, ил хафизларын җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Диния Нәзарәтенең Коръәнне ятлау турында беренче Шәһадәтнамәләре 19 июнь көнне «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тәхфиз (Коръән ятлау) бүлеген уңышлы тәмамлаган 7 укучыга тапшырылды. Шәкертләр, өч ел дәвамында Коръән ятлап, мөфтият комиссиясе каршында имтихан тоттылар.

Шәһадәтнамә Хафс риваяте буенча Гасыйм кыйраәтендә Коръәнне укып, тәҗвид кагыйдәләре белән сөйләп ятлауны тәгаллүгәнен раслый. Шәһадәтнамә гарәп һәм татар телләрендә языла һәм ул Татарстан мөфтие һәм комиссия рәисе имзалары белән беркетелә, мөфтият мөһере куела.

■ dum.rt

# «Хозур ТВ» татар сүзләренең мәгънәләрен аңлата



Татарстан мөселманнары Диния Нәзарәте «Хозур ТВ» беренче мөселман телевидениесендә «Сүз эчендә хикмәт бар» тапшыруы эфирга чыга башлаячак. Татар сүзләренең килеп чыгышына (этимологиясенә) багышланган тапшыруларны Кәрим Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры актрисасы Резеда Сәлахова алып барачак.

Әлеге тапшыру язучы-прозаик, тел һәм мәдәният тарихы белгече Адлер Тимергалиннның «Миллият сүзлеге»нә нигезләнеп эшләнә. Тапшыруда сүзләрнең килеп чыгу тарихы һәм төрле мәгънәләре буенча ачыклыклар кертеләчәк, аның тарихыннан төрле кызыклы вакыйгалар сөйләнәчәк. Сүзләрне телевизор караучылар үзләре өчен төрле яктан ача алачак. Гадәттә, бер тапшыруда 5-6 сүзнең тарихын яктырту күздә тотыла. Һәрбер чыгарылыш татар алфавитының билгеле бер хәрефенә багышланачак. Алып баручы тапшыруда сүзләрнең мәгънәсе хакында гына сөйләп калмый, һәрбер чыгарылыш ахырында шушы хәреф белән бәйле әдипнең биографиясе бәян ителә һәм аның бер-ике әсәре китерелә, аны укып карарга тәкъдим ителә. Мәсәлән, тапшыруларның берсендә Әмирхан Еникинең тормыш юлы белән таныштырырга һәм аның әсәрләре турында сөйләргә ниятлиләр.

Тапшыруның идеясе – татар телен үстерү, ватанпәрвәрлек тәрбияләү, милли мәсьәләләрне күтәрү.

«Сүз эчендә хикмәт бар» тапшыруы июль аеннан эфирга чыга башлаячак.

Исегезгә төшерәбез, Диния Нәзарәте 2020 елны Татарстанда Туган тел елы дип игълан итте. Мөфтият үзенең быелгы бөтен эшчәнлеген мәчетләрдә татар телле мохит булдыру, татар телен өйрәтү, татар рухи мирасын популярлаштыру, халыкта милли үзаңны тәрбияләү, милли үзенчәлекләрне саклап калу кебек максатларны исәпкә алып башкарачак.

■ dum.rt

# ДИН – БӘХЕТКӘ ЮЛ

Безне иң яхшы Белүче – Ул Аллаһы Тәгалә, чөнки Ул безне Яратучы. Ул безне ярата һәм без Аны да, Аның мәхлүкъларын да яратабыз. Ул кайсы гамәлләребез бәхеткә, ә кайсылары бәхетсезлеккә китерәчәген Белүче. Аллаһы безнең бу дөньяда бәхетсез булуыбызны теләми. Шуңа күрә, бәхетле һәм тыныч тормыш яшәсен өчен, безгә пәйгамбәрләрне җибәргән. Пәйгамбәрләр дә нәкъ безнең кебек гади кешеләр булган. Әмма аларны Аллаһы Үзе башкалар арасыннан сайлап алган. Ул аларны Үзенең яклавы астына алып, өйрәткән һәм пәйгамбәрлеккә әзерләгән. Алар киң күңелле, тырыш, гадел, ышанычлы, батыр кешеләр. Барысы да безне Аллаһының диненә өйрәтә. Дин – ул бәхетле тормышка илтә торган юл. Дин буенча яшәүче кеше, иң беренче чиратта, үзенең Яратучысы белән, ә аннары әйләнә-тирәдәгеләр белән мөнәсәбәттә бәхетле була.



## Бу дөнья тормышы – сәяхәт

Бу җир йөзенә килү белән кешенең тормышы башлана. Кеше тормыш юлын акрын гына үтә: үсә, камилләшә, картая. Көннәрдән бер көнне килгән үлем бу җир йөзен калдырып китәргә мәҗбүр итә. Кеше, башка мәхлүкатлардан аермалы буларак, Аллаһыдан бирелгән акылы ярдәмендә үз тормышы белән үзе идарә итә. Әмма акылга ия булса да, ул үзенә үзе тапшырылмаган. Бу тормышта адәм баласы акылга ияреп кенә бәхеткә ирешә алмый. Ул юл күрсәтүче затка мохтаҗ, чөнки бу дөнья сынау урыны булып тора.

Бу тормышта хак юлны күрсәтүче һәм аннан тайпылдыручылар бар. Аллаһының әмерләренә каршы баручы шайтан һәрдаим кешеләрне адаштырырга тырыша. Кешеләрнең тормышларын җимерер өчен, ул төрле мәкерле хәйләләр кора. Аларны юлдан яздырып, начар гамәлләрне яхшы итеп күрсәтә, хакыйкатьтән ераклаштыра, килешмәгән эшләрне башкаруга этәрә. Әмма колларын бик яратучы Аллаһы безнең яман эш-гамәлләрдән ерак торуыбызны тели. Шуның өчен Ул төрле вакытларда Үзенең пәйгамбәрләрен җибәргән. Алар һәрвакыт кешеләргә бәхеткә илтә торган юлны – динне өйрәткән. Әгәр кешеләр пәйгамбәрләрнең сүзләрен тыңласалар, әдәпле һәм бәхетле булып гомер кичерерләр, ә инде шайтанның мәкерлекләренә иярсәләр, бу дөньяда да, киләсе Ахирәт тормышында да кайгыда булырлар.

**«Янә Ул көнне һәм төнне, кояшны һәм айны сезнең өчен әмеренә буйсындырды. Йолдызлар да Аның әмере белән [сезгә] буйсындырылган [өчен, әсләренә йөкләнгән бер вазифаны да үтәми калмыйлар]. Һичшиксез, [зирәклек һәм нечкә аңлау сәләтенә ия булмыйча, фәкать] акыл иясе булган кешеләр өчен монда [могҗизалы] билгеләр бар».**

«Ән-Нәхел / Бал кортлары, 16:12

## Һәркем алдында җаваплылыгыбыз бар

Аллаһы Тәгалә безне һәм бу күркәм дөньяны юкка гына яратмаган. Ул кешеләргә кайбер бурычларны йөкләгән. Җиһандагы бөтен әйбер: бу дөнья, хайваннар һәм тормышыбыз үзебезгә тапшырылган. Һәм безнең болар каршында бурычыбыз бар.

Бурычларыбызны үти алсын өчен, Аллаһы Тәгалә безгә акыл, фикерләү һәм сөйләм сәләте биргән. Без камил рәвештә яшәсен өчен, гаделлек һәм шәфкатьлелек хисләре белән бүләкләгән.

Бу дөньяда күп мәхлүкатлар яши. Үләннәрнең, хайваннарның, кошларның, бөҗәкләрнең, төрле үсемлекләрнең, аллы-гөлле чәчәкләрнең үзләренә генә хас тормышы бар. Ул тормыш кешенекенә охшамаган, әмма аларның яшәеше дә тереклек итү булып санала. Без мәхлүкатларны, безне чорнап алган һәрнәрсәне сакларга тиеш, чөнки без аларның тәрбиячеләре итеп билгеләнгәнбез. Без әлеге мәхлүкълардан үзебезгә тиешлесен алабыз, алардан файда күрәбез. Әмма эш иткәндә аларга зыян салудан һәм Аллаһы Тәгалә билгеләгән кысалардан чыгудан ерак булсак иде.

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында [хакыйкый һәм кабул ителгән] дин – Ислам [дине генә]...».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**«[Фәрештәләрдән, кешеләрдән һәм җеннәрдән] Күкләрдә һәм җирдә булганнар – Аныкы гына, һәммәсе дә [теләсә дә, теләмәсә дә] Аңа буйсына».**

«Рум», 30:26

■ Сәхифәне Айсылу Юлдашева әзерләде

# Тел – Аллаһының нигъмәте

Аллаһы Тәгалә кешеләрдән иң беренче булып Адәм галәйһиссәламне яратты:

**«Адәм Раббысыннан [берникадәр] сүз өйрәнеп, кабул итеп алды [һәм шул сүзләр белән Раббысына ялвара башлады], Ул аның тәүбәсен кабул итте. Һичшиксез, Ул – Тәүбәләрне кабул итүче, Рәхимле».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:37

Һәм Раббыбыз Адәм галәйһиссәламгә зур дәрәҗәләр бирде:

**«Һичшиксез, без сезне [атагыз Адәмне бер балчыктан] яраттык, аннары сезне [атагызны] шәкелләндердек, аннары фәрештәләргә: «Адәмгә сәҗдә кылыгыз», – дидек, алар исә сәҗдәгә киттеләр, Иблис кенә сәҗдә кылучылардан булмады».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:11

Адәм галәйһиссәламгә җан өргәннән соң Хәвва анабызны яратты. Соңрак аларның балалары туды. Һәм алар Җир шары буенча таралды. Адәм балаларының саны артты. Һәм Аллаһы Тәгалә аларны төрле-төрле милләт итте. Ягъни кешеләрнең төрле милләттә булулары, төрле телләрдә сөйләшүләре, тән төсләренең төрлелеге, төрле язмышка дучар булуы – болар барысы да Аллаһы Тәгаләдән. Кешеләр үзләре телләр уйлап чыгармаган, кавемнәргә бүленмәгән. Бүген дә, фән нинди генә үсеш кичермәсен, бер генә кеше дә кайсы милләт вәкиле булып туачагын хәл итә алмый. Аллаһы Тәгалә әмере белән теге яки бу ата белән анадан билгеле бер милләт баласы булып туабыз.

Шуңа күрә безгә үзебезнең милләтебезнең телен, гореф-гадәтләрен белү мәҗбүри. Бу диндә вәҗиб гамәл дәрәҗәсендә йөри. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Әгәр дә шушы җирлектәге халыкның гореф-гадәтләре дингә каршы чыкмаса, ягъни ширеккә китермәсә, бу гадәтләр – ислам гадәте», – дип әйткән. Шуңа күрә күп кенә ислам галимнәре туган телне белүне вәҗиб гамәл дип карый.

## Телне белмәү – зур хилафлык

Аллаһы Тәгалә безгә туган телебезне белергә насыйп итсен иде.

Раббыбыз Үзе «Хуҗурат» сүрәсендә болай дип әйтә:

**«И, кешеләр! Һичшиксез, Без сезне [Адәм исемле] бер ирдән һәм [Хәвва исемле] бер хатыннан яраттык. [Һәммәгезнең дә атаанасы бер булганга күрә, нәселчыгыш белән мактануның ни мәгънәсе бар?] Без сезне [берберегезгә уйламый-нитми теләсә ни сөйләр өчен түгел] танышуыгыз өчен кавемнәр һәм кабиләләр иттек. Аллаһы хозурында иң кадерлегез – [иң асыл нәселдән булганнарыгыз түгел, Аллаһы Тәгаләнең харамнарыннан сакланган] бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз. Һичшиксез, Аллаһы – [һәрнәрсәне] Белүче, [һәрнәрсәдән] Хәбәрдар».**

«Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:13



Моны дөрес аңлау бик мөһим. Раббыбыз тарафыннан безнең төрле милләт вәкилләре булып яратылуыбыз шуның белән масаю, башка милләтләрне кимсетү, хурлау өчен түгел. Үз тамырларыбызны белү, тарихта булган хаталарны кабатламау, шушы җирлектәге халыкларның казанышларын тагын да үстерү өчен кирәк. Бүген Татарстаныбыз биләгән җирлектә инде мең елдан артык Ислам динен тоталар икән, безнең бу чынбарлыкны инкяр итәргә, аннан качарга хакыбыз юк.

Онытмыйк: халкыбыз Совет чорында озак вакыт динсезлектә яшәгән. Бүген менә шул вакыттагы вазгыятьне безгә үрнәк итеп куючылар, безнең әби-бабайлар алай эшләми иде, бу безнең гадәт түгел дип дәлил китерүчеләр бар. Мондый очракта ничек җавап бирергә? Чыннан да, ул вакытта бала булган кешеләр бүген әби-бабай дәрәҗәсендә йөриләр. Бер караганда, алар динле, намазлы, уразалы булырга тиеш. Ләкин күп очракта бу алай түгел. Һәм алар, үзләрен аклар өчен, безнең әби-бабайлар алай итмиләр иде, бу безгә читтән, гарәптән, төректән һ.б. кертелгән йолалар дип әйтәләр. Ни өчен шулай килеп чыккан? Чөнки, беренчедән, ул вакытта илдә динсезлек чоры иде. Анда чыннан да халык диннән ерак иде. Башка идеяләр белән яшәде. Икенчедән, намаз укыса да, садака бирсә дә, әби-бабайлар ул вакытта аны яшерен эшләргә тырыштылар. Күрсәтмичә, ишекне ябып, бу турыда ачыктан-ачык белгертми генә, чөнки вакыты шундый булган. Без шуңа күрә ул чорны аерып карыйк. Совет чорында диннең хәле бик авыр булган. Алай да әби-бабаларыбызның күбесе динен дә, милләтен дә сатмаган, ислам дине йолалаларын кулларыннан килгәнчә саклап калырга тырышкан. Аларның рухлары шат булсын, Аллаһы Тәгалә урыннарын җәннәттә итсен иде.

## ... милләтне дә саклап калу бик авыр булган

Совет чорында безгә бик күп чит гадәтләр кергән. Милләтләр, халыклар бик буталышканнар, катнаш гаиләләр күп булган. «Милләт» төшенчәсен юк итәргә тырышканнар. Мондый шартларда динне дә, милләтне дә саклап калу бик авыр булган.

Әмма Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә Ислам динен Кыямәт көненә кадәр сакларга Үзе вәгъдә бирә. Шуңа күрә дин ул Ахырзаманга кадәрбетмәс. Ә милләт мәсьәләсендә болай дип әйтеп булмый. Ул бетәргә, юкка чыгарга мөмкин. Дөнья тарихында атамалары сакланып калган кавемнәр аз булганмы? Юк. Әле исемнәре безнең чорга кадәр килеп җитмәгәннәре күпме. Аллаһы Тәгалә бу хакта ачыктан-ачык болай дип әйтә:

**«Синең Раббың – Бай [беркемнең дә ярдәменә Мохтаҗ булмаучы] һәм [дини вазифаларына игътибарлы булмауларына карамастан, колларына тәүбәгә килергә вакыт биргән] Рәхмәт иясе. [И, залимнәр һәм баш күтәрүчеләр!] Әгәр Ул теләсә, сезне юк итәр һәм, сезне [Нух галәйһиссәламнең көймә-сендә котылуга ирешкән] башка бер җәмәгатьнең нәселеннән чыгарганы кебек, артыгыздан сезнең урынга теләгәннәрен [итагатьле колларын] куяр».**

«Әнгәм / Терлек», 6:133

Үзегез дә игътибар иткәнегез бардыр. Совет чорындагы фотоларны карасак, анда мәчетләрдә гел татар йөзләре. Ә хәзер мәчетләребездә татарларның саны кими. Башка халык вәкилләре күбрәк. Дин ул милләтсез дә яшәр, югалмас. Ә менә милләт динсез югалыр. Бигрәк тә безнең татар милләтендә телне дә, гореф гадәтләрне дә гомер-гомергә дин саклап килгән.

Шуңа күрә эшләргә кирәкле эшләр әле бик күп. Иң беренче чиратта, динне милләттән аеруны туктатсак иде. Дин аерым, милләт аерым дип ялгышмасак иде. Инкыйлабка кадәрге вакытны искә төшерик. Милләтнең йөзек кашы булган бөтен татар байлары, галимнәре – дини кешеләр булганнар. Мәчетләр салганнар, мәдрәсәләр тотканнар. Бүген бу матур традицияне кайтару кирәк. Фән кешесе дә, эшкуар да, эшче дә – барысы да милләтен дә сөйсен, динен дә онытмасын.

Әле кайчан гына «глобальләшү» сүзеннән сискәнеп китә идек. Инде аңа да ияләштек. Бүген диндә глобальләшү күбрәк икътисад белән бәйле. Чикләр ачылгач, мөмкинлекләр арткач, без хәзер гарәптән, төректән килгән күлмәкләр, яулыклар сатып алабыз, китаплар укыйбыз, чит илләргә йөрибез. Элек бит болар берсе дә булмаган. «Безнең әбиләр мондый яулык япмаган, мондый күлмәк кимәгән», – дигән сүз шуннан да чыга. Ул вакытта андый мөмкинлекләре булмаган. Әбиләребезнең кешелеккә кия торган матур бер күлмәге, бер яулыгы гына булган. Әйдәгез, бүген дә кызларыбыз, хатыннарыбызның гардеробында шундый милли рухлы, чигелгән яулыклар, күлмәкләр булдырыйк. Моңа бит беркем дә комачауламый. Әгәр дә сорау булса, тәкъдим итүчесе дә табылыр иде. Милләтебезнең дини гореф-гадәтләре шул киенү әдәбеннән үк башлана. Галәм дәрәҗәсендәге мәсьәләләрдән түгел.

**Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы**

# Эстония мөселманнары: татарларның төньяк Балтыйк буе илләренә ислам динен алып килүләре

Бер уйлап караганда, Ислам дине һәм әлеге кечкенә ил арасында бернинди дә уртаклык юк сыман. Чынлыкта исә, Эстония һәм ислам илләре арасында күптәннән килгән элемтә барлыгын күрәбез. Нәкъ менә мөселманнар беренче тапкыр Җир йөзе картасында Эстония җирләрен билгеләгән. Гарәп географы Мөхәммәд Әл-Идриси (тулы исеме: Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Мөхәммәд Әл-Идриси, 1110-1166) Көнбатыш Аурупа, Төньяк Африка һәм Кече Азия буйлап сәяхәт кылган.

Ул, Сицилия патшасы Роджер II исеменнән, дөнья картасын сызып, аларда күрсәтелгән илләрнең географиясе һәм тарихы турында аңлатмалар биргән. Әлеге хезмәт «Әл-Китаб Әр-Руджжари» яки «Роджер китабы» дип атала. Биредә автор Эстония һәм Таллин (элеккеге исемнәре Колывань/Колуван, Ревель) турында мәгълүмат биргән.

Картаның тасвирламасында болай дип язылган: «Анхель – бик матур һәм чәчәк ата торган шәһәр. Ул Астланда җирләренеке. Аның шәһәрләренә тагын Колуван шәһәре дә керә. Калкансыман кыяфәттә булган әлеге шәһәр аз. Халкы җир эшкәртүчеләр, аларның керемнәре зур түгел, әмма терлекләре күп. Ул Анхельдән көньяк-көнчыгышка таба алты көн ераклыгындагы җирдә тора. Һәм, әгәр дә яр буйлап барсаң, Анхельдән 50 миль ераклыгында Берну елгасы тамагы урнашкан».

Астланда җирләре – ул Эстония, Колуван-Таллин, Берну-Пярну елгасы. Ә Анхель дигәндә, бүгенге көнге Эстониянең Ханила шәһәре күз алдында тотыла. Тарихи яктан караганда, Эстониягә Ислам динен, борынгы бабалары 922 елдан динне кабул иткән Идел болгарларыннан булган, татар халкы алып килгән. Ливон сугышы (1558–1583) вакытында, элеккеге Казан һәм Әстерхан ханлыкларыннан булган Касыйм татарлары, хәзерге Эстония территориясендә рус гаскәрләре белән берлектә сугышырга мәҗбүр булганнар.

Татарлар еш кына әлеге территориягә ия булган Швеция ягына күченгәннәр. Соңрак бер өлеше Эстония районнарының яр буендагы урыннарыннан җирләр алган. Алга таба биредәге халык белән кушылып, аларга охшый башлаганнар.

Беренче эре ислам җәмгатьчелеге, озак вакыт Рәсәй белән Швеция арасында дәвам иткән, Төньяк сугышыннан (1700-1721) соң оешкан. 1721 елдагы тынычлык килешүе нәтиҗәсендә Рәсәй империясенә Эстония һәм Латвия да кушыла. Рус гаскәрләре сафларында татар-мөселманнар да сугыша һәм алга таба биредә яшәргә кала.

Ул вакытларда армия хезмәте 25 елны тәшкил иткән. Күпләр үзләре белән гаиләләрен алып килгән, ә хезмәтләре тәгәлләнгәннән соң бу җирләрдә бөтенләйгә яшәргә калган. Шул рәвешле, Эстониядә, ә барыннан да бигрәк Таллинда (ул вакытта Ревель дип аталган) мөселманнар тотрыклы рәвештә яши башлаган. Һәм Эстониядә нәкъ менә хәрби татар-мөселманнар беренче мөселман җәмгатьчелегенә нигез салган.

Төньяк сугышы тәмамланганнан соң татарлар торак биналары өчен җир ала башлый. Алар тыгызлап урнашырга тырышканнар. Бу урыннарны Таллин халкы татар кварталы дип атый башлый. Иң баштан, XVIII гасырда әлеге районда татар гарнизоннарының казармалары урнашкан була. Ә бистәнең казарма урнашкан үзәк урамы Татари (Татар урамы) дип атала башлый.

Бу атама бүгенге көндә дә сакланып калган. Таллинда үзенең шәхси урамы булуы белән беркем дә: даниялеләр дә, шведлылар да, немец халкы да мактана алмый. Гәрчә алар шәһәрнең барлыкка килүе һәм үсеше өчен үз өлешләрен кертсәләр дә. Ә менә мондый хокукка ия булган татар халкының ике урамы булган: Татари һәм Уус-Татари урамнары.

Хәзер бу урын Татари микрорайоны дип атала һәм ул шәһәрнең үзәк районында урнашкан. Инде XIX гасырның азагына әлеге район шәһәрнең иң дәрәҗәле районнарының берсенә әйләнә. Бүгенге көндә Татари микрорайонында нык тормышлы шәһәр кешеләре яши. Шулай ук биредә мөһим объектлар: Эстон музыка һәм театр академиясе, «Космос» кинотеатры һәм Эстониядә АКШ илчелеге урнашкан.

■ **Мөхсин Нурулла язмасы, islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә**





# Гыйбрәтле хикәяләр

Муса галәйһиссәлам Аллаһы Раббыбыздан: «Җәннәттә урыным кем белән янәшә булыр икән?» – дип сорагач, Аллаһы Раббыбыз аңа бер шәһәрдә ит чабучыны эзләп табарга куша. Муса галәйһиссәлам әлеге кешене эзләп таба һәм алар ит чабучының өенә кайталар. Өйгә кереп дога кылгач, ит чабучы Муса галәйһиссәламне калдырып, түр якка кереп китә һәм анда шактый гына торып чыга. Муса галәйһиссәлам: «Кунакны калдырырлык нинди мөһим эшең бар иде?» – дип сорый. Моңа каршы ит чабучы: «Анда минем авыру әнием ята, хәлен белдем, астын алыштырдым, ашаттым», – дип җавап кайтара. Муса галәйһиссәлам: «Әниең берәр сүз әйтмәдеме?» – дип сорагач, әлеге кеше: «Әйе, әнием, җәннәттә урының Муса галәйһиссәлам янәшәсендә булсын иде, дип дога кылды», – дип әйткән.

* * *

Берәү, хатыныннан зарланып, Гомәр радыяллаһу ганһегә бара. Барса, ни күрсен, Гомәр радыяллаһу ганһене хатыны пыр туздырып, әрләп маташа, ул дәшми генә тыңлап тора икән. «Моның хәле минекеннән мөшкел икән», – дип, теге кеше кире борылып китә. Гомәр радыяллаһу ганһе аның артыннан куып җитеп: «Ни йомыш иде?» – дип сорый. «Хатынның холкыннан зарланып килгән идем, синең хәл дә мактанырлык түгел икән, ничек сабыр итәсең?» – дип сорый теге кеше. «Хатыным мине зинадан саклый, ашарга әзерли, киемнәремне юа, өйне тәртиптә тота, балаларымны тәрбияли… Ничек инде мин аннан риза булмыйм?!. Аллаһы хатын-кызга акылны ирләргә караганда кимрәк, хисне артыграк биргән. Җавап кайтарсам, аңа карaганда да акылсызрак булам бит», – дип җавап бирә Гомәр радыяллаһу ганһе.

* * *

Бер кеше әүлияне күрергә теләп, янына бара. Барса, әүлия үзе юк, хатыны гына өйдә икән. Әлеге кешенең нинди йомыш белән йөргәнен белгәч, хатын, ярсып: «Шул диванадан әүлия ясадыгыз инде. Үзе булдыксыз, үзе ялкау, кулыннан бер эш килми. Җитмәсә, шул җүләрне күрергә киләләр», – дип, ирен эткә әйтмәгән сүзләр белән тетеп ташлый. Кунак бик аптырап китеп бара. Юлда берәүнең утын алып кайтып килүен күрә. Әлеге кеше әүлия була. «Минем янга килгән идеңме? Ул хатын белән ничек тора икән дип, аптырап китеп барасыңмы?» – дип, эчке рухияте белән кунакның бөтен халәтен аңлап, сорый. Һәм җавап та көтмичә: «Шул хатынның холкына сабыр итеп торганым өчен Аллаһы миңа әүлиялек бирде, нәфесемне җиңәргә ярдәм итте, шуның өчен мин аңа бик рәхмәтле», – дип сүзен йомгаклап та куя.



* * *

Бер хатын иреннән зарланып, казыйга бара, аерылырга тели.

Казый әлеге хатынның моңзарларын тыңлый һәм: «Син миңа ипи пешереп китер. Ипи пешергәндә, кирәкле әйберләрне күршеләреңнән ал. Шуннан соң мин синең ирең белән сөйләшермен», – дип әйтә. Хатын, сөенеп, өенә кайтып китә һәм, камыр басарга су сорап, күршесенә керә. Күрше хатыны: «Үзеңнеке юкмыни, ник безгә кердең?» – ди. Хатын хәлне аңлатып биргәч, күрше хатыны: «И җүләр, шундый ирдән аерылалармени? Син менә минем җүнсез белән торып кара», – дип, үз ирен хурлый, ә күршесенекен мактый башлый. Он сорап кергән күршедә дә, тоз сорап кергән күршедә дә шул ук хәл кабатлана. Җиденче күршесенә чүпрә сорап кергән бу хатынга үз ире инде фәрештә булып күренә башлый.

Хатын, ипи пешереп, казыйга килә һәм: «Хәзрәт, бу ипи сезгә бүләк булсын, мин иремнән аерылмыйм. Минем иремнән дә начаррак ирләр белән яшәүче хатыннар бар икән», – дип әйтә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Начарлыкны карамагыз, начарлыкны тыңламагыз, сөйләмәгез, әгәр шулай эшләсәгез, начарлык шуннан куәт алыр һәм сез начарлыкны таратучы булырсыз», – дип әйткән. Димәк, һәркайсыбыз бер-беребезнең яхшы ягын күрә, сөйли белергә тиеш, шулвакытта башкалар да яхшыга үзгәрер. Күрше хатыннары күргән яхшы якларны үз хатыны моңарчы күрмәгән. Без бит яхшылыкка тиз ияләнәбез, шулай тиеш дип кабул итәбез. Кечкенә генә начарлыкны да киңәйтеп, зурайтып сөйләргә яратабыз.

«Сабыр иткән – морадына җиткән», – ди халык мәкале.

* * *

Бер әти кеше, улыннан зарланып, Гомәр радыяллаһу ганһе янына килә. Гомәр радыяллаһу ганһе аннан баласының исемен сорый. Исеме «җүләр» дигән мәгънәне белдерә икән. Шулай ук баланың әтисеннән: «Буш вакытта нишлисең, балаңа дини гыйлем бирәсеңме?» – дип сорый. Әлеге кеше: «Буш вакытым булса, мин җырларга, музыка тыңларга яратам, балама берни дә өйрәтмим», – дип җавап кайтара. «Әнисе белән мөнәсәбәтегез ничек?» – дип кызыксына Гомәр радыяллаһу ганһе. «Ачуым чыккач, әнисен аерып, куып җибәрдем», – дип әйтә әлеге кеше. Гомәр радыяллаһу ганһе: «Синең бала тәрбияләвең хайваннардан аерылмый икән. Баланың матур исем йөртергә, хәләл ризык ашарга, күркәм дини тәрбия алырга, тулы гаиләдә яшәргә, үз тиңенә никахланырга хакы бар. Әнә ишәк, ат, дөя бара. Балаң, шул хайваннар белән бутап, берүк сиңа суга күрмәсен», – дип әйткән.

* * *

Баласыз хатын бер ананың яшь баласын урлый. Бала анасы, сабыен эзләп табып: «Бу минем балам, кире кайтар», – дип әйтә. Урлаган хатын: «Юк, бу бала минеке», – дип дәгъва кыла. Мәсьәләне хәл итәр өчен, алар Сөләйман галәйһиссәлам янына баралар. Сөләйман галәйһиссәлам биләүдәге баланы бер бүкән өстенә яткыра да, кылычлы сакчыны чакырып китереп: «Шул баланы урталай чап та, яртысын бу хатынга, ә яртысын икенчесенә бир», – дип әйтә. Баланың үз анасы «аһ» дип кычкырып җибәрә һәм: «Бу минем балам түгел, әнә теге хатынга бирегез», – дип, баласының гомерен саклар өчен, иң кадерле йөрәк җимешеннән баш тарта. Сөләйман галәйһиссәлам: «Баласыннан баш тартканы – аның чын әнисе, баланы шуңа бирегез», – дип хөкем чыгара.

Ана кеше бала хакына бар авырлыкка да түзәргә әзер.

* * *

Базарда ике дөя басып тора, яннарында бер дөя баласы чабып йөри, ди. Дөянең хуҗалары килгәч, алар арасында бәхәс чыга. Берсе: «Бу минем дөямнең баласы», – ди, икенчесе: «Юк, минеке», – ди. Уртак фикергә килә алмагач, бер галимне чакырып, мәсьәләне хәл итәргә булалар. Галим, дөя баласын көймәгә салып, тирән суга кереп китә. Бер дөя шунда ук суга сикерә. Хайваннар арасында дөя йөзә белми торган хайван санала, шуңа да карамастан, ул тирән суга сикерә. «Бала – суга сикергән дөянеке», – дип нәтиҗә ясый галим.

Хайваннарда бала дигән хис бик көчле, баласы өчен хайван үләргә тора. Әмма үсеп җиткәч, хайваннарда әти-әни дигән хис калмый. «Ана күңеле –балада, бала күңеле – далада», – ди халык мәкале. Балаларыбызда әти-әни дигән хис булсын дисәк, «кешедән ким булмасын» дип түгел, «кеше булсын» дип, Аллаһы Тәгалә кушканча тәрбиялик.

* * *

Бер сәхабә елап, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аннан: «Нәрсә булды?» – дип сорый. Сәхабә: «Әнием үлде», – дип җавап кайтара. «Әниең намаз укымый идеме әллә, тәмугка эләгер дип борчыласыңмы?» – дип сорый Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм. «Әнием иманлы, намаз укучы, ураза тотучы мөслимә иде, урыны җәннәт түрендәдер, аның өчен борчылмыйм. Ул миңа җәннәткә капка иде. Аңа хезмәт итеп, җәннәтне кәсеп итә идем. Догасы афәтләрдән, бәла-казалардан саклый торган калкан иде. Җәннәткә алып баручы юлым киселде, саклаучы калканымны югалттым», – дип җавап кайтара әлеге сәхабә.

«Әти-әнинең, мосафирның, мәзлумның догасына киртә юк» (хәдис).

■ **Җәлил хәзрәт Фазлыевның «Күңел бакчасы» китабыннан**

# Әбү Хәнифә – бөек имам

Фикһ өлкәсендәге иң зур галимнәрнең берсе. Хәнәфи мәзһәбенең нигезен тәшкил иткән хезмәтләр авторы. Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать гакыйдәсен таратуда үз өлешен керткән галим. Бу сүзләр барысы да бөек шәхес Әбү Хәнифә хакында.



**Чын исеме: Ногъман**
**Әтисенең исеме: Сабит**
**Яшәгән еллары: 80/690 – 150/767**

### Әбү Хәнифә һәм гаилә

Әбү Хәнифә мөселманнар арасында Имам Әгъзам, ягъни бөек имам буларак билгеле булган. Аның чыгышы хакында төгәл мәгълүматлар сакланмаса да, гарәпләр арасында туып-үсүе, ләкин гарәп булмавы билгеле.

Әти-әнисе Әбү Хәнифәдә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам гаиләсенә карата – ярату, мәхәббәт, ә дингә карата ихласлык һәм дингә карата эчкерсезлек тәрбиялиләр.

### Әбү Хәнифә һәм белем

Куфа шәһәрендә укыган беренче елларында ук Әбү Хәнифә Изге Коръәнне яттан өйрәнә. Шул ук вакытта морфология (сарф) һәм синтаксис (нәхү) кебек фәннәрне һәм гарәп әдәбиятын үзләштерә. Шул чорда яшәгән белгечләрдән сабак ала, аларның чыгышларын тыңлый, хәдисләр өйрәнә һәм Ислам хокукы кебек фәнне өйрәнә.

Әбү Хәнифә мантыйк ягыннан башкалардан аерылып тора. Фикер алышу һәм бәхәсләр вакытында аңа тиңнәр булмый. Бәхәсләрнең берсендә Куфа шәһәренең бөек галиме Әбү Әмра Әш-Шагъбины да җиңә. Мондый эшчәнлек нәтиҗәсендә Әбү Хәнифә искиткеч бөеклекләргә ирешә.

Әлеге осталыгы Әбү Хәнифәне якын-тирәгә бик тиз арада таныта. Шул ук вакытта Басра һәм Куфә шәһәрендә Кәлам фәне бик киң таралган була. Әбү Хәнифә әлеге фәнне дә бик яхшы үзләштерә.

### Әбү Хәнифә һәм остазлар

Әбү Хәнифәнең 16 яшендә әтисе белән бергә Хаҗга баруы һәм хәдис белгечләреннән сабак алуы билгеле. Үзенең «Мөснәд» хезмәтендә, сәфәр вакытында сәхабәләрнең берсе – Габдулла бине Җөз Әз-Зәбирдене очрату турында яза. Гыйракта булганда, күп кенә танылган табигыйннәр белән очрашкан. Шуңа бәйле рәвештә, Әбү Хәнифә табигыйн түгел, ә табигыйннәрнәң дәвамчысы булып санала. Гәрчә тормышында сәхабәләрне очратса да.

### Әбү Хәнифә һәм сәүдә

Төрле дини бәхәсләрдә катнашу һәм гыйлем алу белән беррәттән, Әбү Хәнифә сәүдә белән дә шөгыльләнә. Ул Һиндстан, Иран һәм Гарәп ярымутравының сәүдә юллары киселеше булган, теләсә нинди фикер Ислам күзлегеннән анализланган атаклы Басра шәһәренә егермедән артык сәүдә сәфәре ясый.

### Әбү Хәнифә һәм остазлык

Соңрак, фикһ белән җитди яктан мавыгып китеп, Әбү Хәнифә (үз вакытында Әш-Шәгъби һәм Ибраһим Ән-Нәхагый (96/714) шәкерте булган) Хаммәд бине Әби Сөләйманның (120/737) дәвамчысы булып куя. Укытучысы вафат булгач, 40 яшьлек Әбү Хәнифәгә дәресләр алып барырга һәм фәтвалар бирергә туры килә. Әбү Хәнифәнең укытучылык эше 30 елга сузыла. Укучыларының күбесе бөек имам – мөҗтәһид дәрәҗәсенә ирешә. Әбү Йосыф (158/774) һәм Мөхәммәд бине Хәсән Әш-Шәйбани (189/805) кебек күренекле укучылары фикһ белеменә бик зур өлеш кертәләр.

### Әбү Хәнифә һәм сәясәт

Шул заманның күп кенә күренекле галимнәре кебек ук, Әбү Хәнифә Аллаһы Тәгалә илчесенең гаиләсенә һәм нәселенә тирән ихтирам белән карый. Әмәвиләр, аннары Габбасилар идарәсен яратып бетерми. Шуңа күрә үзенә тәкъдим ителгән дәүләт вазифаларыннан берничә тапкыр баш тарта. Габбасилар династиясенең икенче җитәкчесе Әбү Җәгъфәр Әл-Мансур, Әбү Хәнифәнең баш тартуын кабул итмичә, аны зинданга ташлаттыра. 15 көн зинданда ятканнан соң, Әбү Хәнифә 70 яшендә (150/767 елда) вафат була.

### Әбү Хәнифә һәм ислам

Әбү Хәнифә Аллаһы Илчесенең үзеннән чыккан нәрсәләрне берсүзсез кабул иткән. Табигыйннәрнең иҗтиһадларына иярмәгән. Иҗтиһадка бәйле үз фикере, үз тәртибе булган: Китап, Сөннәт, сәхабәләрнең сүзләре, кыяс, истихсан, иҗмәгъ һәм гореф-гадәтләр.

### Әбү Хәнифә һәм фән

Әбү Хәнифә фикһ буенча аерым мөстәкыйль хезмәтләр язмаган. Бөек имамның фикерләре чагылдырылган барлык китапларны да, Әбү Хәнифә вафатыннан соң, укучылары туплый.

**1. «Әл-Фикһел-әкбар».**

Бу Әбү Хәнифәнең улы Хаммад тарафыннан язылган иң танылган хезмәт. Әлеге әсәрнең безнең көннәргәчә килеп җиткән бер-берсеннән өлешчә аерылып тора торган 3 версиясе бар. Бу хезмәткә Әбү Мансур Әл-Матуриди җитәкчелегендә төрле галимнәр тарафыннан бик күп шәрехләр языла. Әсәр күп тапкырлар төрек теленә тәрҗемә ителгән. Әлеге китапта Ислам дине нигезләре кыска, ләкин җентекле рәвештә тасвирлана.

**2. «Әл-Фикһел-әбсат».**

Әлеге хезмәт Әбү Хәнифәнең улы Хаммәд һәм укучылары Әбү Йосыф һәм Әбү Мө’ти бине Габдулла Әл-Бәлхи тарафыннан тапшырыла. Китапның кулъязма нөсхәләре Каһирә китапханәсендә саклана (VII/353). Китапка Гата Әл-Җөрҗәни исемле галим шәрех яза.

**3. «Әл-Галим вәл-мутәгаллим».**

Бу хезмәттә Әбү Хәнифәнең укучысы Әбү Мокатил биргән сорауларга җаваплары тәкъдим ителә. Китапның кулъязмалары шулай ук Каһирә китапханәсендә (VII/553) саклана. Әл-Паздавиның «Усуль» китабына керештә «Әл-Галим вәлмутәгаллим» хезмәтенең авторы Әбү Хәнифә булуы хәбәр ителә.

**4. «Әр-Рисалә. Әбү Хәнифәнең Госман Әл-Баттыйга мөрәҗәгате».**

Әлеге китап Басра шәһәре галиме Әбү Госман Әл-Баттыйга юлланган була. Китапта мөрҗиидләрнең (Ислам динендәге юнәлешләрнең берсе. Әлеге агым вәкилләре, игелек кылу кяферләргә файда китермәгән кебек, гөнаһ кылу мөселманнарга зыян китерми дигән фикердә торалар) фикерләре инкяр ителә. Әл-Паздавиның китабына керештә «Әр-Рисалә» хезмәтенең авторы Әбү Хәнифә булуы хәбәр ителә. Әлеге китапның кулъязма нөсхәләре Каһирә китапханәсендә саклана (VII/203, 553).

**5. «Әбү Хәнифәнең васыяте».**

Әлеге хезмәтнең кулъязма нөсхәләре Аурупа Һәм Мисыр китапханәләрендә (V/264) табылган. Бу китапка Мулла Хөсәен бине Искәндәр Әл-Хәнәфи, Акмаледдин Әл-Бабирти һәм Әл-Һәдими кебек галимнәр тарафыннан шәрехләр язылган була. Әл-Бабирти шәрехенең кулъязма нөсхәсе Төркиянең Нуру Госмания, Айа-София, Баязит һәм Сәлим-ага китапханәләрендә саклана.

■ **Сәхифәне Айгөл Абдрахманова әзерләде**

# ӘНИ димим...

*Дәвамы. Башы алдагы санда*



...Көннәр үтте, атналар, айлар бербер артлы артта калды, көн саен телевизордан Сашаның рәсемен күрсәтеп, адресны кабатлауга карамастан, малайның әти-әнисе күренмәде.

Саша Айназ белән Айвазга ияреп татарча сөйләшергә өйрәнде, тик яңа гаиләгә бик авыр ияләште. Кыңгырау чыңлаган саен ишек төбенә йөгереп барып әти-әнисен көтте. Айсылуны көн дә диярлек «Балалар дөньясы»на әйдәде, баруга, үзе онытып калдырылган йомшак уенчыклар бүлегенә чапты, аннан инде бичара малайны кибет ябылганчыга кадәр алып китеп булмый иде. Әмма ни гаҗәп: «Куян» исемле песине Айназдан да ныграк яратты Саша.

Айсылу исә баланы нишләтергә белмичә гаҗизләнде: ятимнәр йортына тапшырырга кызганды, сабыйны махсус ташлаганнар дигән рәхимсез дөреслек белән һич тә килешә алмый иде ул. Аннары инде Сашаны уллыкка алуны рәсмиләштерделәр. Әтиләре Алмаз да каршы килмәде, алар җитешле тормышта яшиләр, өченче баланы тәрбияләрлек мөмкинлек бар иде.

...Еллар үтте. Саша аз сүзле, басынкы, тыныч малай булып үсте. Әмма, буш вакыт тигән саен, «Балалар дөньясы»на йөгерүе гадәт булып калды. Айсылу белән Алмаз «улым» дип дәшсәләр дә, аны Айназ белән Айваздан һичкайчан аерып карамасалар да, Саша бер генә тапкыр да, хәтта ялгышып та «әти», «әни» дип әйтмәде. Беренче күргәндәгечә, малай өчен алар һаман «тетя», «дядя» булып калды. Саша гел үзенекеләрне көтеп яшәде...

Туган көнен Айназ белән бергә, үзе табылган көнгә билгеләделәр. Ләкин Саша кызчыктан гәүдәлерәк булып, таза, матур булып үсте, яңа әтиәнисенә әллә ни мәшәкать тудырмады. Кечкенәдән шахмат белән мавыкты, яхшы укыды, малайның ни җитте гаиләдән түгел икәнлеге дә ачык аңлашыла иде.

...Айсылуны уйларыннан бүлеп, сискәндереп, ишек кыңгыравы чылтырады. Кунакларны каршы алырга йөгергән Айназның яңгыравык тавышы шактый аптыраулы ишетелде: «Сезгә кем кирәк?»

«Әниеңә өйдәдер бит», – дигән ят тавыш Айсылуны да ишек катына чакырды. Бусагада озын буйлы чибәр яшь хатын басып тора иде. Ананың йөрәге, нindидер көтелмәгән хәл буласын сизенгәндәй, кысылып куйды. Шулай да чакырылмаган кунакны түргә дәштеләр.

«Мин Сашаның әнисе булам», – диде ханым, бер мизгелгә генә Айсылуның күзләренә текәлеп. Ана телсез калды.

– Ник? Ничек әнисе буласыз? Тугыз ел буе кайда йөрдегез соң сез? – дип сорау арты сорау яудырды ул, бераз сөйләшерлек хәлгә килгәч. – Балагыз турында ник бүген генә искә төшердегез? Ни өчен шушы вакытка кадәр бер хәбәрегез дә булмады?

– Дәрәҗәле фирма ирем белән икебезгә Европага барып эшләргә тәкъдим ясады, өч елга контракт төзеде; анда берничек тә бала белән барырга ярамый иде, шунлыктан без малайны берәр балалар йортына тапшырып китәргә уйладык, – дип, бик гадәти әйбер турында сөйләгән кебек кенә сүз башлады хатын, Айсылуны тыныч кына тыңлап торгач. – Ә аны, бездә ятимнәр дә күп, дип, беркайда да алырга теләмәделәр, югыйсә вакытлыча гына иде бит. Шуннан инде ирем бу хәлдән чыгуның үзенчәлекле юлын тапты: зур шәһәргә илтеп, берәр җирдә калдырыйк та кем алып киткәнен карап торыйк, илгә кайткач, өйгә кабат алырбыз, дип уйлаштык һәм тиз үк тормышка да ашырдык. Калганы инде сезгә мәгълүм. Сез, зинһар, мине дөрес аңлагыз, анда бармый калырга һич ярамый иде. Әмма без чит илдә озаграк тордык, өстәвенә анда туган кызыбыз да гомерле булмады, дүрт яшь тулып килгәндә, урамда машина бәрде үзен. (Шул мәлдә, Айсылуны чиксез гаҗәпләндереп, аның кара күзләрендә яшь тамчысы күренде). Бу улыбызны, инде шактый вакыт та үткәч, оныткан да шикелле идек, тирәндә калган йөрәк яраларын яңартып йөрмәскә уйлаган идек... Ләкин табиблар, башкача балаң булмаячак, диләр. Әмма миңа бала кирәк! Бирегез миңа үз улымны! Сезнең тагын икәү бар бит...

Залда тынлык урнашты. Айсылуның башы эшләми иде, мондый хәлләр буласын күз алдына да китермәде бит ул! «Ичмасам, әтиләре дә кайтып җитми», – дип өзгәләнде ана, чарасызлыктан ни кылырга да белмичә. Балаларның да тавыш-тыны чыкмый, өлкәннәр сөйләшкәндә, алар комачаулап йөрмиләр.

– Саша зур инде, ни эшләргә кирәклекне үзе хәл итсен, ул ничек әйтсә, шулай булыр, – диде Айсылу үзе дә көтмәгәндә, малайның һаман да әле «әни» дип дәшмәвен хәтерләп.

– Әйе, нәкъ бер айдан аңа 13 яшь тула, – Нинаның тавышы калтырап китте, – мин аның нindирәк икәнен да күз алдыма китерә алмыйм бит, йә Ходаем!

«Менә ни өчен торттагы шәмнәрнең саны артык чыккан икән!» дигән уй белән, ана, көч-хәл кузгалып, балалар бүлмәсенә китте. Шахмат тактасына иелгән малайга бермәл моңаеп карап торгач, Сашаның иңнәреннән кочты: «Бар, улым, сине әниең чакыра...»

Малайның күзләрендә шатлык та, чиксез гаҗәпләнү дә берьюлы чагылып китте, ни әйтергә белми бераз утыргач, кинәт сикереп торып, кунак бүлмәсенә атылды. Айсылу исә, хәлсезләнеп, Сашаның урындыгына сыгылып төште. Бераздан, үзен кузгалырга мәҗбүр итеп, зал ишегенә килде, әмма керергә кыймады; сагаеп калган балалары янына үтеп, кызын кочаклады да аның йомшак чәчләренә битен куйды. Тик ул халәттә дә озак тора алмады, кунак бүлмәсенә кабат барды, азрак таптанып торгач түзмәде, ишекне кинәт ачып кереп китте.

Саша диван кырыена гына утырган, үтәли карашы әнисенә «кадалган», үзе бер сүз дә дәшми; хатын исә гаепле тавыш белән сөйли дә сөйли...

«Юк, сез минем әнием түгел, әни димим, әни диялмыйм мин сезгә, әнием мине ташламаган булыр иде, ничә еллар буе бер дә күрмичә түзә алмас иде!»

Уларының бу кадәр катгый хөкеменнән ике ана да катып калды. Ул арада Саша атылып-бәрелеп чыгып йөгерде, урамга ук чапты бугай, тышкы ишек тә шапылдап ябылды.

Беренче булып ят хатын телгә килде: «Ярый, мин китим, без бөтенләй чит кешеләр икән, ул инде хәзер минем балам түгел...» Ханым ашыкмыйча гына урыныннан кузгалды, авыр атлап ишек янына җиткәч рәхмәт әйтте һәм акрын гына чыгып китте. Айсылу һаман аңына килеп бетмәгән иде. Ярый әле балалары әнкәләрен ике яклап кочып алганнар да бер сүз дәшмиләр.

Шулай күпме торган булырлар иде, кинәт ишек ачылды, анда, ишек яңагына сөялеп, Саша басып тора иде. Аны күрүгә, Айсылу елап җибәрде. Малай аның янына йөгереп килде һәм, «Әнием!» – дип, ананың кочагына сыенды.

■ **Нурзилә (Нурзидә Нотфуллина)**

**Хөрмәтле радиотыңлаучылар!**

"Азан" радиосы сайтының адресы үзгәрде. Хәзер безне azan.fm сылтамасы буенча таба аласыз. Иске мобиль кушымталар да үз эшен туктатты, аларны яңарту кирәк. Моның өчен, айфоннарда – App Store, андроидларда Play Market’ка кереп, "Азан радиосы" дип җыеп, "обновить" төймәсенә басарга кирәк. (Әгәр моңарчы телефоныгызда безнең кушымта булмаган булса, бер дә шикләнмичә куегыз). Әзер! Хәзер сез кая гына барсагыз да, бернинди түләүсез рәхәтләнеп татарча дини радио тыңлый аласыз.

**QR – кодлар:**

Android өчен:

iPhone өчен:

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Сайт:** | azan.fm | **Телеграм-канал:** | azanfm |
| **Инстаграм:** | azan.fm | **Почта:** | radio@azan.fm |
| **Вконтакте:** | azanfm | **Тел.:** | 8 (843) 598-09-43 |

## ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ, ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ

| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Хәзрәткә сорау |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Әд-дин вә әдәп |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълиматы |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Азан |
| 12:30-14:00 | Кәлам Шәриф – мәгънәви тәрҗемә |
| 14:05-14:15 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 14:20-14:27 | Мәчетләребез тарихы |
| 14:30-14:40 | Сөннәт юлы |
| 14:45-14:50 | Әд-дин вә әдәп |
| 14:55-15:10 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 15:15-15:20 | Хәзрәткә сорау |
| 15:25-15:30 | Әхлак баскычлары |
| 15:45-15:48 | Миллият сүзлеге |
| 16:00-16:20 | Коръән тәфсире |
| 16:25-16:27 | Көндәлек догалар |
| 16:30-16:40 | Таян Аллаһка |
| 16:50-17:00 | Иман тәме |
| 17:05-17:08 | Миллият сүзлеге |
| 17:10-17:15 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 17:20-17:25 | Әд-дин вә әдәп |
| 17:50-17:57 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 18:00-18:15 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 18:30-18:45 | Күңелдән күңелгә |
| 18:50-19:00 | Тынычлык тәгълиматы |
| 19:05-19:15 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 19:20-19:35 | Бәхет тулы йорт |
| 19:40-19:45 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 19:50-20:05 | 101 вәгазь |
| 20:10-20:15 | Көндәлек догалар |
| 20:20-20:35 | 40 хәдис |
| 20:40-20:43 | Миллият сүзлеге |
| 20:45-20:55 | Намаз дәресләре |
| 21:00-21:03 | Нәниләргә нәсыйхәт |
| 21:20-21:30 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 21:40-21:47 | Мәчетләребез тарихы |
| 21:50-21:55 | Хәзрәткә сорау |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 22:25-22:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |

## ҖОМГА

| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Җомга тәбриге |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Әд-дин вә әдәп |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 8:50-8:55 | Җомга тәбриге |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълиматы |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:30-11:35 | Җомга тәбриге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Азан |
| 12:30-14:00 | Кәлам Шәриф – мәгънәви тәрҗемә |
| 14:05-14:15 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 14:20-14:27 | Мәчетләребез тарихы |
| 14:30-14:40 | Сөннәт юлы |
| 14:45-14:50 | Әд-дин вә әдәп |
| 14:55-15:10 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 15:15-15:20 | Җомга тәбриге |
| 15:25-15:30 | Әхлак баскычлары |
| 15:45-15:48 | Миллият сүзлеге |
| 16:00-16:20 | Коръән тәфсире |
| 16:25-16:27 | Көндәлек догалар |
| 16:30-16:40 | Таян Аллаһка |
| 16:50-17:00 | Иман тәме |
| 17:05-17:08 | Миллият сүзлеге |
| 17:10-17:15 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 17:20-17:25 | Әд-дин вә әдәп |
| 17:50-17:57 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 18:00-18:15 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 18:30-18:45 | Күңелдән күңелгә |
| 18:50-19:00 | Тынычлык тәгълиматы |
| 19:05-19:15 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 19:20-19:35 | Бәхет тулы йорт |
| 19:40-19:45 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 19:50-20:05 | 101 вәгазь |
| 20:10-20:15 | Көндәлек догалар |
| 20:20-20:35 | 40 хәдис |
| 20:40-20:43 | Миллият сүзлеге |
| 20:45-20:55 | Намаз дәресләре |
| 21:00-21:03 | Нәниләргә нәсыйхәт |
| 21:20-21:30 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 21:40-21:47 | Мәчетләребез тарихы |
| 21:50-21:55 | Хәзрәткә сорау |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 22:25-22:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |

*Тапшырулар арасында эфирда кыска хәдисләр, нәшидләр һәм мөнәҗәтләр яңгырый




## Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәковның «Төзек булсын никахлар» китабы дөнья күрде

ТҖ мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәковның «Төзек булсын никахлар» («Счастливая семейная жизнь») китабын бастырды.

Әлеге китап кеше тормышында зур роль уйный торган вакыйга – никах, гаилә кору турында бәян итүгә багышланган. Автор бу мәсьәләдә укучыларны кызыксындырган четерекле сорауларга җавап бирә, гаиләдә бер-береңне аңлап, хөрмәт итеп яшәүнең серләренә төшендерә. Китап бөхетле гаилә коруның, сәламәт буын тәрбияләүнең мөһимлеге турында Коръән аятьләре һәм динебез аша аңлатылуы белән бәһале. Авторның бу хезмәте яңа тормыш корырга җыенучы парлар өчен дә, гаиләле кешеләр өчен дә файдалы булыр дип өметләнәбез.

Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан заказ бирергә мөмкин.

**Кибет:** Казан шәһ., Тукай ур., 36нчы йорт.
Тел.: +7(903) 305-45-43
**Склад:** Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт.
Тел.: +7 (966) 250-00-09
**Интернет-кибет:** huzurshop.ru
(http://huzurshop.ru/)/





**« Дин вә мәгыйшәт» газетасына 2020 елның икенче яртыеллыгына язылу башланды**

- Ярты елга язылу бәясе: 156 сум
- Газета айга бер тапкыр чыга
- Язылу индексы: П4333

Түбәндәге сайтларда да язылу мөмкин:
podpiska.pochta.ru һәм uslugi.tatarstan.ru
сайтының «Подписка» бүлегендә.

дин вә мәгыйшәт

Белешмәләр өчен телефон:
+7 (843) 598 09 42


**КАЗАН ӨЧЕН ИЮЛЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ**

| Көн | Сәхәр тәмам/ иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ ифтар | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.07.2020 | 01:03 | 03:03 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 |
| 02.07.2020 | 01:04 | 03:04 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 |
| 03.07.2020 | 01:05 | 03:05 | 12:00 | 17:34 | 20:29 | 21:59 |
| 04.07.2020 | 01:06 | 03:06 | 12:00 | 17:33 | 20:29 | 21:59 |
| 05.07.2020 | 01:07 | 03:07 | 12:00 | 17:33 | 20:28 | 21:58 |
| 06.07.2020 | 01:08 | 03:08 | 12:00 | 17:33 | 20:27 | 21:57 |
| 07.07.2020 | 01:09 | 03:09 | 12:00 | 17:32 | 20:26 | 21:56 |
| 08.07.2020 | 01:10 | 03:10 | 12:00 | 17:32 | 20:25 | 21:55 |
| 09.07.2020 | 01:11 | 03:11 | 12:00 | 17:32 | 20:24 | 21:54 |
| 10.07.2020 | 01:13 | 03:13 | 12:00 | 17:31 | 20:23 | 21:53 |
| 11.07.2020 | 01:14 | 03:14 | 12:00 | 17:31 | 20:22 | 21:52 |
| 12.07.2020 | 01:15 | 03:15 | 12:00 | 17:30 | 20:21 | 21:51 |
| 13.07.2020 | 01:17 | 03:17 | 12:00 | 17:30 | 20:20 | 21:50 |
| 14.07.2020 | 01:18 | 03:18 | 12:00 | 17:29 | 20:19 | 21:49 |
| 15.07.2020 | 01:20 | 03:20 | 12:00 | 17:28 | 20:18 | 21:48 |
| 16.07.2020 | 01:21 | 03:21 | 12:00 | 17:28 | 20:16 | 21:46 |
| 17.07.2020 | 01:23 | 03:23 | 12:00 | 17:27 | 20:15 | 21:45 |
| 18.07.2020 | 01:24 | 03:24 | 12:00 | 17:26 | 20:13 | 21:43 |
| 19.07.2020 | 01:26 | 03:26 | 12:00 | 17:26 | 20:12 | 21:42 |
| 20.07.2020 | 01:27 | 03:27 | 12:00 | 17:25 | 20:10 | 21:40 |
| 21.07.2020 | 01:29 | 03:29 | 12:00 | 17:24 | 20:09 | 21:39 |
| 22.07.2020 | 01:31 | 03:31 | 12:00 | 17:23 | 20:07 | 21:37 |
| 23.07.2020 | 01:32 | 03:32 | 12:00 | 17:22 | 20:06 | 21:36 |
| 24.07.2020 | 01:34 | 03:34 | 12:00 | 17:21 | 20:04 | 21:34 |
| 25.07.2020 | 01:36 | 03:36 | 12:00 | 17:20 | 20:02 | 21:32 |
| 26.07.2020 | 01:37 | 03:37 | 12:00 | 17:19 | 20:00 | 21:30 |
| 27.07.2020 | 01:39 | 03:39 | 12:00 | 17:18 | 19:59 | 21:29 |
| 28.07.2020 | 01:41 | 03:41 | 12:00 | 17:17 | 19:57 | 21:27 |
| 29.07.2020 | 01:43 | 03:43 | 12:00 | 17:16 | 19:55 | 21:25 |
| 30.07.2020 | 01:45 | 03:45 | 12:00 | 17:15 | 19:53 | 21:23 |
| 31.07.2020 | 01:46 | 03:46 | 12:00 | 17:14 | 19:51 | 21:21 |


**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Июнь саны, №6 (299)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2750
Газетага ярты елга язылу бәясе – 156 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 26 нчы июньдә таратыла.
График буенча бу санга 22 нче июнь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.